СИШӘМБЕ
27 ФЕВРАЛЬ
1940 ел
№ 47 (5847)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ: Казан, Матбугат йорты. ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

Тоташтан грамоталы республика өчен!

Шушы елның 25 нче июнендә орденлы Татарстан республикасының төзелүенә егерме ел тула. Кешелекнең бөек даһилары В. И. Ленин һәм И. В. Сталин инициативасы буенча төзелгән Татарстан Автономияле Совет Социалистик республикасы үзенең егерме еллыгын гаять зур уңышлар белән каршылый. Бөек большевиклар партиясе һәм Совет хөкүмәте җитәкчелегендә республикабыз, кыска гына вакыт эчендә, танымаслык булып үзгәрде. Элекке Казан губернасында хөкем сөргән политик хокуксызлык, хәерчелек, экономик артталык мәңгегә юк ителделәр. Ленин—Сталин милли политикасының өзлексез рәвештә тормышка ашырылуы нәтиҗәсендә Татарстан республикасы Советлар иленең алдынгы индустриаль-аграр республикаларының берсе булып әверелде. Промышленность, авыл хуҗалыгы, социалистик культура чәчәк ата.

Республикабызның хезмәт ияләре данлыклы егерме еллыкка гаять зур күтәренкелек белән хәзерләнәләр. Эшчеләр, колхозчылар, интеллигентлар бу бөек бәйрәмне яңа уңышлар белән каршылау өчен сугышчан рәвештә көрәшәләр. Заводларда һәм фабрикаларда, колхозларда һәм совхозларда стахановчылык хәрәкәте көннән-көн көчәя бара.

Хезмәт ияләре республикабызның социалистик культура өлкәсендә булган уңышларын тагын да арттыру өчен үз өсләренә конкрет йөкләмәләр алалар. Укый-яза белмәүчелекне бәйрәм көненә тәмам бетерү өчен көрәш — бу, йөкләмәләрдә киң урын ала. Тоташтан грамоталы республика өчен! Хезмәт ияләренең үзләре тарафыннан көн тәртибенә куелган гаять зур әһәмиятле бурычларның берсе әнә шул.

Бу өлкәдә безнең ирешкән уңышларыбыз, һич шиксез, күп. Бары тик үткән елны гына да 63 мең кеше үзенең укый-яза белмәүчелеген бетерде. Аз укый-яза белүчеләр арасыннан 45 мең кеше үз белемен тагын да күтәрүгә ирешкән. Хәзерге вакытта бездә тоташтан грамоталы авыллар саны берәмләп кенә түгел, йөзәрләп санала.

Тоташтан грамоталылык өчен көрәштә Тымытык районы аеруча зур уңышларга иреште. Районның партия һәм совет оешмаларының конкрет җитәкчелек итүләре һәм бу эшне дөрес оештыра белүләре нәтиҗәсендә, район тоташтан грамоталы булу алдында тора. Биредә бары тик 87 кеше укый-яза белми. Хәзер алар да укуга тартылганнар һәм үзләренең укый-яза белмәүчелекләрен бетерү өчен зур тырышлык белән көрәшәләр. 2.039 кеше татар язуының рус графикасы нигезендә төзелгән яңа алфавитын өйрәнү түгәрәкләрен тәмам итте. Бу түгәрәкләрдә тагын 2.010 кеше укый.

Ләкин орденлы Татарстан республикасын бөек Ватаныбызның тоташтан грамоталы республикасына әверелдерү өчен бу уңышлар безне канәгатьләндерә алмыйлар әле. Республикабызның кайбер районнарында укый-яза белмәүчелекне бетерү эше тиешле дәрәҗәдә оештырылмаган. Куйбышев, Чүпрәле, Балык Бистәсе, Кукмара районнарының җитәкчеләре бу политик мәсьәләгә җитәрлек әһәмият бирмиләр. Чүпрәле районында укый-яза белмәүчеләрнең саны 2.000 нән артык. Алардан бары тик 580 кеше укуга тартылган. Куйбышев районында 1.900 кешедән 92 кеше укый. Балык Бистәсе районында 1.669 кеше урнына 774 кеше укуга тартылган, ләкин алар да дәрескә тулысы белән йөрмиләр. Бу районның Зур Әшнәк авылында 200 укый-яза белмәүче хисаплана. Авылда укытучылар көче дә аз түгел. Тулы булмаган урта мәктәп директоры иптәш Борһанов, ВКП(б) райкомының һәм райсовет башкарма комитетының бу турыда берничә күрсәтмәсе булуына да карамастан, укый-яза белмәүчеләрне укыту эшен кирәгенчә оештырганы юк әле.

Кукмара районында хәлләр тагын да начаррак.

Укый-яза белмәүчелекне тәмам бетереп, тоташтан грамоталы республикага ирешү мәсьәләсе партия, совет, профсоюз, комсомол оешмалары алдында торган иң җаваплы бурычларның берсе. Бу өлкәдә намус белән, чын-чыннан большевикларча эшләү—ул һәрбер совет гражданының мактаулы эше. Партиябезнең тарихи XVIII нче съезды тарафыннан куелган политик бурычны—хезмәт ияләрен коммунистик тәрбияләү бурычын хәл итүдә укый-яза белмәүчелекне бетерү эшенең роле гаять зур.

Укый-яза белмәүчелекне бетерү эшенә оператив җитәкчелек, чыгарылган карарларның үтәлешен үз вактында һәм системалы тикшерү—партия, совет һәм комсомол оешмаларыннан әнә шул таләп ителә. Социалистик ярыш һәм алдынгыларның эш тәҗрибәләрен уртаклашу тоташ грамоталылык өчен көрәштә киң урын алырга тиеш.

Республикабызда партиянең район конференцияләре башланды. Бу конференцияләр укый-яза белмәүчелекне бетерү эшенә киң урын биреп, районнарны һәм, шулай ук, республикабызны данлыклы юбилейгә тоташтан грамоталы итү өчен конкрет чаралар билгеләрләр дип ышанырга кирәк.

БОЛГАРИЯ ИЛЧЕСЕ Т. ХРИСТОВ ӘФӘНДЕНЕҢ ЫШАНЫЧ ГРАМОТАЛАРЫН ТАПШЫРУЫ

25 нче февральдә СССР Верховный Советы Президиумы Председателе иптәш М. И. Калинин Болгариянең гадәттән тыш илчесе һәм тулы хокуклы министре Т. Христов әфәндене кабул итте. Т. Христов әфәнде үзенең ышаныч грамоталарын тапшырды.

ШВЕЦИЯ ИЛЧЕСЕ В. АССАРССОН ӘФӘНДЕНЕҢ ЫШАНЫЧ ГРАМОТАЛАРЫН ТАПШЫРУЫ

25 нче февральдә СССР Верховный Советы Президиумы Председателе иптәш М. И. Калинин Швециянең гадәттән тыш илчесе һәм тулы хокуклы министре В. Ассарссон әфәндене кабул итте. В. Ассарссон әфәнде үзенең ышаныч грамоталарын тапшырды.

Ак Финляндиягә ярдәм күрсәтүгә каршы хәрәкәт

НЬЮ-ЙОРК, 25 февраль. (ТАСС). Атлантадан (Георгий штаты) „Дейли уоркер“ газетасының хәбәр итүенә караганда, „Атланта уорлд“ газетасы, Яңа Орлеонда яшәүче негр халкы гуверов комитетының негр мәктәп балалары арасында ак Финляндиягә ярдәмгә средство җыярга маташуына каршылык күрсәтә, дип хәбәр итә. „Атланта уорлд“ газетасы Маннергейм Финляндиясе өчен средство җыюга каршы кискен рәвештә каршы чыга.

„Дейли уоркер“ газетасының шушы көннәрдә генә хәбәр итүенә караганда, Лос-Анжелоста мәктәп чиновниклары, ак Финляндиягә ярдәм итү буенча гуверов фондына средство кертсеннәр өчен балаларга басым ясыйлар. Газетаның күрсәтүенә караганда, Лос-Анжелосның эшчеләр яши торган районнарында гуверов агентларының кампаниясе җимерелгән.

ЛЕНИНГРАД ХӘРБИ ОКРУГЫ ШТАБЫНЫҢ ОПЕРАТИВ СВОДКАСЫ

25 нче февральдә Карелия бугазында безнең частьләр, дошманның ныгытмаларын үтеп, 28 ныгытылган оборона пунктын алдылар. Шуларның 8 е тимер-бетоннан ясалган артиллерия корылмалары. Дошманның безнең частьләргә каршы атака ясарга күп тапкыр маташулары кире кагылды. Дошман зур югалтуларга дучар ителде.

Фронтның башка участкыларында әһәмиятле үзгәрешләр булмады.

Безнең авиация күп кенә районнарда дошман гаскәрләрен уңышлы рәвештә бомбага тотты. Һавада булган сугышларда дошманның 10 самолеты бәреп төшерелде.

Чит илләрдә

КӨНБАТЫШ ЕВРОПА СУГЫШЫ

БРЮССЕЛЬ, 24 февраль. Франциядә чыга торган „Журналь“ газетасының 24 нче февральдәге хәрби күзәтүендә болай диелә: „Фронтта җирдә дә, һавада да көчле хәрәкәт булды. Ләкин фронт арасындагы полосада патрульләр һәм разведка зур бәрелешләр алып бармадылар. Һавада дошман белән бәрелеш булмады. Очышлар фронт линияләре өстендә дә, тылда да булды“.

Англия самолетларының Германиянең 2 самолетын бәреп төшергәнлекләрен күрсәтеп, газета, Англия өстендә һәм Төньяк диңгез өстендә сугыш хәрәкәтләре башланганнан бирле Германия авиациясенең барлыгы 50 самолетын югалтканлыгын хәбәр итә.

Газета болай дип яза: „Диңгездә дә көчле сугыш хәрәкәте күренде. Англичаннар балык тота торган бер карабларын югалттылар. Икенче бер карабка Германия самолетлары атака ясадылар“.

Аннары газета Германиянең су асты флоты хәрәкәтләренең көчәйгәнлеген һәм „Германиядә соңгы вакытта күп кенә яңа су асты көймәләре төзелгәнлекне“ күрсәтә.

БЕРЛИН, 24 февраль. Германия информация бюросы хәбәр итә: „Көнбатыш фронтта әһәмиятле бер нәрсә дә булмады. Истребительләрнең һәм зенит артиллериясенең хәрәкәте үткән көннәргә караганда ике якта да җанлырак булды. Германия самолетлары Франция өстендә разведка очышлары ясадылар. Төнлә Германия территориясе өстендә дошманның разведка самолетларының очуы күренде“.

БЕРЛИН, 25 февраль. Германия армиясенең верховный командованиесе хәбәр итә: „Мозель белән Пфальц урманы арасында җиңелчә артиллерия һәм разведка хәрәкәте. Германия самолетлары Франция—Германия чигендә һәм Германия бухтасында патрульлек иттеләр. Англиянең бер самолеты һәм Франциянең бер самолеты бәреп төшерелде.

Германия авиациясе бер самолетын да югалтмады. Сугыш башланганнан алып 1940 нчы елның 20 нче февраленә кадәр Германия хәрби диңгез флотының операцияләре нәтиҗәсендә дошманның һәм союзниклар өчен йөк ташучы нейтраль илләрнең 496 пароходлары батырылды“.

ПАРИЖ, 25 февраль. Гавас агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Англия самолетлары Гельголанд атавына, Германиянең зур хәрби порты Вильһелемсгафенга якынайганнар һәм Германиянең төньяк районнары өстендә очканнар. Төньяк диңгездә Англия самолетлары Германиянең 2 су асты көймәсенә атака ясаганнар. Франциянең хәрби даирәләрендә бу су асты көймәләренең батырылганлыгын раслыйлар.

Франция самолетлары разведка һәм күзәтү ясап, дошман позицияләрен фотографияләп алдылар. Германия самолетлары төркем-төркем булып Югары Эльзас районы өстендә һәм Швейцария чикләре буйлап очтылар. Алар шулай ук Франциянең көнчыгыш һәм төньяк районнары өстендә дә, хәтта Париж районына кадәр очып, күп санда тирән разведка очышлары ясадылар. Болардан тыш Германия самолетлары Англия ярлары юнәлешендә 20 рейд ясаганнар.

Франциядә 24 нче февральдә кич иглан ителгән белдерүдә болай диелә: „Бөтен фронтта көн тыныч үтте. Рейндә азрак атышу сизелде“.

Бүгенге иртәнге белдерүдә „фронтта әһәмиятле бер нәрсә дә булмады“ диелә.

ЛОНДОН, 25 февраль. Англиянең 2.266 тонна авырлыгындагы „Роял арчер“ пароходы кичә Шотландия ярлары буенда минага бәрелеп баткан. Команданың коткарылган членнары арасында яраланган 14 кеше бар.

Даниянең 1.200 тонна авырлыгындагы „Аэсе“ пароходы Испаниядән Англиягә барганда баткан. Сәбәбе билгеле түгел. Англия ярлары буена дулкын бер көймәне китереп чыгарган. Бу көймәдә пароход капитанының үле гәүдәсе һәм бик нык ябыккан яшь матрос табылган. Команда членнарыннан калган 15 кеше хәбәрсез югалган.

Англиянең 400 тонна авырлыгындагы „Харлей“ пароходына юлда Германиянең 2 самолеты һөҗүм иткән. Самолетлар аңа бомба ташлаганнар һәм пулеметлардан атканнар.

Англиянең 352 тонна авырлыгындагы „Беневолио“ траулеры минага бәрелеп баткан. 10 кешелек команда хәбәрсез югалган. (ТАСС).

„НЕЛЬСОН“ ЛИНКОРЫНЫҢ ЗАРАРЛАНУЫ ТУРЫНДА „ФЕЛЬКИШЕР БЕОБАХТЕР“

БЕРЛИН, 25 февраль. (ТАСС). „Фелькишер беобахтер“ газетасы үзенең 24 нче февральдәге номерында Англиянең хәрби диңгез флотының флагман карабы „Нельсон“ линкорының 1939 нчы елның декабрь урталарында сафтан чыгарылганлыгы хәзер маглүм булганлыкны хәбәр итә. Карабка нык зиан килгән һәм ул шушы көнгә кадәр ремонтта ята. „Фелькишер беобахтер“ның язуына караганда, „Нельсон“ линкоры „Родней“ линкоры белән бер типта булган һәм дөньядагы иң куәтле линкор булган. „Нельсон“ линкорының кораллары 40,6 сантиметрлы 9 орудиедән, 15,2 сантиметрлы 12 орудиедән һәм 25 зенит орудиесеннән тора. Карабның 2 торпеда аппараты бар иде. Аларның диаметры 60,9 сантиметр. Карабның авырлыгы 34 мең тонна. Командасы 1.320 кеше. „Нельсон“да самолетлар очып китү өчен бер катапульта бар. Карабның йөреш тизлеге—23,5 узел.

БЕРЛИН, 25 февраль. (ТАСС). Германия информация бюросының хәбәр итүенә караганда, Италиянең бөтен матбугаты Англия хәрби диңгез флотының флагман карабы „Нельсон“ линкорының бик нык зарарлануы турындагы хәбәрләрне сенсацияле төстә иглан итә. Газеталар диңгез сугышында Германиянең зур уңышлары турында язалар.

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

(ТАСС хәбәрләреннән)

КӨНЬЯК КЫТАЙДА

Гуанси провинциясендә, Наньнин—Умин шоссесендә кытай частьләре 21 нче февральдә берничә пунктны алганнар. Наньнин—Биньян секторында сугышлар дәвам итә. Кытай гаскәрләре Сяодун белән Датан арасында Наньнин—Циньчжоу шоссесе буйлап 30 километрдан артык ераклыкта булган барлык биеклекләрне алганнар.

Амойдан көньяк-көнбатыштарак сугышлар дәвам итә. Курчак хөкүмәтнең бу районындагы барлык гаскәрләре диярлек Кытай хөкүмәте ягына чыкканнар һәм японнарга каршы сугышалар.

23 нче февральдә японнарның берничә эскадрильясе Гуанси провинциясендә Лючжоу шәһәрен бомбага тоткан. Самолетлар күп кенә бомба ташлаганнар. Аларның күбесе шәһәр читенә төшкән һәм зарар китермәгән.

ҮЗӘК КЫТАЙДА

Цзянси провинциясендә япон гаскәрләре Нанкин—Уху тимер юлы районында кытай партизаннарына һәм регуляр кытай частьләренә каршы җәза операцияләре үткәрәләр.

Хунань провинциясендә 21 нче февральдә кытайлар Хубэй һәм Хунань провинцияләре чигендә, Иочжоудан 15 километр төньяктарак японнар отрядына атака ясап, 3 сәгать сугышканнан соң аларны тар-мар иткәннәр. Японнар отряды сугыш кырында 300 ләп үлгән һәм яраланган кешеләрен һәм күп кенә сугыш кирәк-яракларын калдырып чигенгән.

ТӨНЬЯК КЫТАЙДА

Суйюань провинциясенең көнбатыш өлешендә кытай гаскәрләре, Уйюань тирәсендәге районнарны японнардан чистартып, Баотоуга таба баралар һәм чигенеп баручы япон частьләрен эзәрлеклиләр. Соңгы атнада япон самолетлары Суйюань провинциясенең көнбатыш өлешендә тыныч халыкка 3 тапкыр бомбалар ташладылар. Бомбалар ташлау вактында химик бомбалар да кулланылды.

ХАНЬКОУНЫ БОМБАГА ТОТУ

ЧУНЦИН, 25 февраль. (ТАСС). 24 нче февральдә кытай самолетлары Ханькоуда аэродромга һәм япон гаскәрләре штабына бомба ташладылар. Кытай самолетлары һичбер зиансыз үз базаларына кайттылар. Һөҗүм итү турында әлегә тулы мәглүматлар юк.

Бүген ВКП(б) Үзәк Комитеты члены һәм СССР Верховный Советы Президиумы члены Надежда Константиновна Крупскаяның үлүенә бер ел тулды.
РӘСЕМДӘ: Н. К. Крупская (1936 нчы елгы рәсем). (ТАСС фотохроникасы).

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ

Академик А. Е. Фаворскийны Хезмәт Кызыл байрагы ордены белән бүләкләү турында

Тууына 80 ел һәм гыйлми-педагогик эшенә 55 ел тулу уңае белән, күренекле галим, химик-органик, академик Алексей Евграфович **Фаворскийны Хезмәт Кызыл байрагы** ордены белән бүләкләргә.

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе М. КАЛИНИН.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре А. ГОРКИН.

Москва, Кремль.
25 февраль, 1940 ел.

ССР СОЮЗЫ ОРДЕННАРЫ ҺӘМ МЕДАЛЬЛӘРЕ ТАПШЫРУ

ЛЕНИНГРАД, 22 февраль. (ТАСС). Кичә, 21 нче февральдә, СССР Верховный Советы Президиумының тапшыруы буенча, хезмәт ияләре депутатларының Ленинград шәһәр советы башкарма комитеты председателе иптәш П. С. Попков, Ленинград Хәрби Округы Политуправлениесе начальнигы урынбасары бригадный комиссар иптәш Я. Х. Абрамовның һәм Политуправлениенең башка работникларының катнашы белән, Кызыл Армиянең бүләкләнгән сугышчыларына, командирларына һәм политработникларына орденнар һәм медальләр тапшырды. Фин ак гвардеецларына каршы көрәш фронтында командованиенең сугыш заданиеләрен үрнәк булырлык итеп үтәгән өчен һәм шул вакытта батырлык һәм геройлык күрсәткәне өчен кызыл армеец И. М. Соломонников, кече командир В. П. Бахвалов, полковник В. Н. Кошуба, кече командир М. А. Ларченко иптәшләр Советлар Союзы Герое исме бирелү турында грамота, Ленин ордены һәм „Алтын Йолдыз“ медале алдылар.

Фин ак гвардеецларына каршы сугышларда батырлык һәм геройлык күрсәткән өчен кызыл армеец З. П. Швец, өлкән лейтенант Г. Г. Мирошников, кече лейтенант Н. И. Старченко, кече командир П. Я. Глушков, лейтенант Е. В. Здесенко, политрук С. И. Иванов, лейтенант И. Е. Кубатко, өлкән лейтенант Д. И. Милехин, өлкән лейтенант И. С. Мильто, кече политрук С. И. Никифоров, өлкән лейтенант В. А. Стародубцев, лейтенант С. Ф. Чмутов, В. В. Якимов иптәшләр „Кызыл Байрак“ ордены алдылар.

Кече лейтенант иптәш Н. М. Зимингә һәм капитан Р. В. Кряжевка „Батырлык өчен“ медале, кызыл армеец И. К. Шумановка „Сугышчан хезмәтләре өчен“ медале тапшырылды.

Бүләкләнүчеләр исменнән партиягә, хөкүмәткә һәм иптәш Сталинга кайнар рәхмәт һәм чын күңелдән бирелгәнлек белдереп Советлар Союзы Герое полковник В. Н. Кошуба, Советлар Союзы Герое кече командир М. А. Ларченко, „Кызыл Байрак“ ордены белән бүләкләнгән кече политрук С. И. Никифоров һәм башкалар чыгып сөйләделәр. Алар киләчәктә дә командованиенең нинди генә заданиесен дә үз-үзләрен аямыйча үтәячәкләре һәм социалистик Ватанның дошманнарын рәхимсез тар-мар итәчәкләре турында ышаныч белдерделәр.

❖

ЛЕНИНГРАД, 25 февраль. (ТАСС). 24 нче февральдә Ленинградның С. М. Киров исемендәге Кызыл Армия Йортында Ленинград хәрби округының бүләкләнгән сугышчыларына, командирларына һәм политработникларына орденнар һәм медальләр тапшыру булды. Алар фин ак гвардеецларына каршы көрәш фронтында командованиенең сугыш заданиеләрен үрнәк булырлык итеп үтәгән өчен һәм шул вакытта батырлык һәм кыюлык күрсәткән өчен бүләкләнгәннәр.

„Кызыл байрак“ ордены лейтенант Абдиевичкә, майор Балашовка, лейтенант Борисовка, капитан Голиадзега, капитан Зоенковка һәм башкаларга бирелә.

Майор Зеленцовка, 1 нче ранг воентехник Кияшкога, лейтенант Храпковка, батальонный комиссар Яковенкога һәм башкаларга „Кызыл Йолдыз“ ордены бирелә.

Аннары бүләкләнүчеләргә „Батырлык өчен“ һәм „Сугышчан хезмәтләре өчен“ медальләре бирелә.

Бүләкләнүчеләр исменнән батальонный комиссар Л. И. Яковенко сөйли. Ул бөек бүләк өчен партиягә, хөкүмәткә һәм иптәш Сталинга чын күңелдән рәхмәт белдерә һәм совет очучыларының киләчәктә дә ак фин бандитларын рәхимсез тар-мар итәчәкләренә ышандыра.

ПАРТИЯ ТОРМЫШЫ

Партиянең район конференцияләре

ЛЕНИН РАЙОНЫНДА

Партиянең Ленин район конференциясе зур оешканлык белән дәвам итә.

Партиянең район оешмасы отчет чорында 71,4 процентка үскән. Башлангыч партоешмаларның саны 15 тән 29 га җиткән. Районда агитация эшләрен оештыру, промышленность төзелешен алып бару һәм культура учреждениеләрен үстерү буенча шактый эшләр башкарылган. Райком аппаратына, партиянең түбәнге оешмаларына һәм хуҗалык органнарына 120 дән артык кеше күтәрелгән. ВКП(б) Өлкә Комитетының секретаре Гафиятуллин, ВКП(б) Шәһәр Комитеты секретаре Бычков, райком секретарьлары Ананьев һәм Филиппов, ТЭЦ ның баш инженеры Мөхеттинов иптәшләр районның предприятиеләрендә, түбәнге эшләрдә эшләп җитәкче постларга күтәрелгән коммунистлар.

Иптәш Ананьев отчет докладын 2 сәгат 30 минут сөйләде. Ләкин ул, райкомның күп кенә җитешсезлекләрен кирәгенчә ачып бирмәде, аларга тиешле анализны ясамады. Доклад буенча чыгып сөйләүчеләр докладчының һәм райкомның кимчелекләрен конкрет фактлар белән тәнкыйть итәләр.

— Докладчы,—ди иптәш Новосельский,—стахановчылык хәрәкәте турында, күп станокчыларның эшләре турында, кадрларны тәрбияләү турында бер сүз дә әйтмәде. Чөнки райком работниклары бу турыда үзләре дә ачык белмиләр, алар заводларда бик сирәк булалар. Райкомның түбәнге партоешмалар белән элемтәсе йомшак.

Иптәш Сокунов җирле Советларга сайлаулардан соң райкомның агитаторлар эшенә җитәкчелек итүне онтуын, хәзер берничә генә агитколлектив эшләвен күрсәтеп үтте.

Партия сафларын төп профессия эшчеләре хисабына үстерү эше белән дә райком бик йомшак шөгыльләнгән. Партия членлыгына кандидат итеп алынган иптәшләр арасында эшчеләр 23 кенә процент булуы моңа ачык мисаль.

Иптәш Попондопулло үзенең чыгышында, райкомның комсомолга системалы рәвештә җитәкчелек итмәве, актив комсомолецларны партиягә алу эшенең начар баруы турында сөйләде.

Оешмада аерым коммунистлар тарафыннан партия дисциплинасын бозу фактлары бар. Отчет чорында 25 кеше партия документын югалткан, ә кайбер коммунистлар 3—4 ай буена членлык взносларын түләмәгәннәр. Ә райком бу фактлардан үзенә кирәкле нәтиҗәне ясамаган, андый коммунистларга карата тиешле чараны күрмәгән.

Фикер алышуларда катнашучы коммунистларның күбесе партия пропагандасы эшенә райкомның канәгатьләнмәслек җитәкчелек итүен күрсәтеп, күп кенә фактлар китерделәр.

Иптәш Шувалов үзенең чыгышында болай диде:

— Партия пропагандасы турында докладчы читләтеп үтү очраклы хәл түгел. Чөнки райком хуҗалык мәсьәләләре белән йомшак шөгыльләнгән кебек, политик тәрбия мәсьәләләре белән дә бик аз шөгыльләнде. Докладчы райондагы кайсы предприятие планны ничек үтәве турында да ачык әйтмәде. Политик эшне хуҗалык бурычлары белән бергә бәйләп алып бара белмәү нәтиҗәсендә шундый хәл килеп чыкты.

Делегатлардан Бикбов, Ялмаев, Шакуров иптәшләр райсовет, прокуратура, суд һәм районның башка оешмаларына райкомның тиешенчә җитәкчелек итмәвен тәнкыйтьләп чыктылар һәм эшлекле тәкъдимнәр керттеләр.

Миңнул.

МАМАДЫШ РАЙОНЫНДА

25 нче февральдә Мамадыш район партоешмасының конференциясе ачылды. Конференциягә тавыш бирү хокукы белән 73 һәм киңәш бирү хокукы белән 31 делегат катнаша. Конференция почетлы президиумга ВКП(б) Үзәк Комитетының Политбюро составын сайлады.

ВКП(б) райкомы секретаре иптәш Вахрушев отчет доклады ясады. Ул үзенең докладында партия оешмасының үсешенә тукталып, болай диде:

— Узган елгы отчет - сайлау җыелышы вактына безнең оешмада 139 член һәм 72 кандидат бар иде. Хәзер 229 член һәм 177 кандидат исәпләнә. ВКП(б) ның XVIII нче съездыннан соң 57 кеше ВКП(б) члены итеп һәм 142 кеше кандидат итеп кабул ителде. Коммунистларның 13 проценты хатын-кызлар. Отчет чоры эчендә райком аппаратына җитәкче эшкә 14 кеше күтәрелде. Шуларның 3 се хатын-кызлар. Совет эшенә 58 кеше күтәрелде.

Иптәш Вахрушев комсомол оешмаларының эше турында фактлар китерде. Районда комсомол оешмаларының күпчелеге ВКП(б) ның XVIII нче съезды карарларын дөрес аңлаганнар. Партиянең башлангыч оешмалары булмаган колхозларда (Белый ключь, Игенче авылларында) комсомол оешмалары политик-масса эшләрен оештыруда аеруча зур активлык күрсәтәләр. Комсомолецлар язгы чәчүгә хәзерлектә зур эш алып баралар.

Ләкин докладта тәнкыйть һәм үзеңне тәнкыйтьләү җитәрлек булмады. Докладчы пропаганда һәм агитация бүлегенең, хәрби һәм оештыру - инструкторлык бүлекләренең эшләре турында, марксизм-ленинизм теориясен үзләштерү өстендә җитәкче активның, шул исәптән райком секретарьларының ничек эшләүләре турында бер сүз дә әйтмәде.

Райком секретаре иптәш Вахрушев докладыннан соң, конференция ВКП(б) райкомының ревизия комиссиясе докладын тыңлады. Шуннан соң һәр ике доклад буенча фикер алышулар башланды.

КУЗНЕЧИХА РАЙОНЫНДА

Кузнечихада партиянең район конференциясе бара. ВКП(б) райкомы секретаре иптәш Нырков үзенең докладында, партиянең район оешмасы отчет чорында шактый үскәнлеген, башлангыч партоешмалар саны бермә-бер артканлыгын күрсәтеп үтте. Бу чорда партия сафларына 226 кеше кандидат итеп һәм 81 кеше член итеп кабул ителгән. Яңа кабул ителүчеләр арасында 108 комсомолец һәм 21 хатын-кыз бар. 194 коммунист, 343 комсомолец һәм 111 партиясез активист ВКП(б) тарихын үзлекләреннән өйрәнәләр.

Фикер алышуларда Нуруллин („Рационализатор" заводы), Иванов (Кузнечиха МТС ы) һәм башка иптәшләр катнаштылар. Алар яшь коммунистлар арасында райкомның начар эшләвен нык тәнкыйтьләделәр. Районның хәрби комиссары иптәш Панов хәрби бүлек мөдире иптәш Шагалинның райком тарафыннан колхозларга вәкил итеп җибәрү өчен генә файдаланылуын, оборона-масса эшләре белән шөгыльләнмәвен күрсәтте. (ТатТАСС).

Партия органнарына сайлауларда беренче тапкыр катнашучы яшь коммунистлардан бер төркем (В. И. Ленин исемендәге завод). Сулдан уңга—Е. Н. Меркулова, В. Н. Васильев, Д. Н. Строкин, И. Г. Похвалинский һәм М. У. Гумеров иптәшләр. В. Лужбин фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

КИРОВ РАЙОНЫНДА

Кичә, иртәнге сәгать 10 да, Культура сараенда, Киров районы большевикларының конференциясе эшли башлады. Конференциядә тавыш бирү хокукы белән 225 делегат, киңәш бирү хокукы белән—51 делегат катнаша. Район партактивыннан конференциягә 38 кеше кунак булып килгән. Конференция эшендә ВКП(б) Үзәк Комитетының Татарстан буенча парторгы Павлов, ВКП(б) Өлкә Комитеты секретаре Долотказин һәм ВКП(б) ның Казан Шәһәр Комитеты секретаре Нацибуллин иптәшләр катнашалар.

Озакка сузылган кул чабулар астында почетлы президиумга иптәш Сталин һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты Политбюросының башка члennары сайланалар.

Конференция үзенең җитәкче органнарын сайлаганнан соң практик эшкә керешә.

Отчет чорында ВКП(б) ның Киров райкомы эше турында райком секретаре иптәш Тихонов доклад ясады. Конференция райкомның ревкомиссиясе председателе иптәш Гумеровның да отчет докладын тыңлады.

Конференциянең кичке утырышында һәр ике доклад буенча фикер алышулар башланды.

Ишкәев.

Консультацияләрнең сыйфатын яхшыртыйк

ВКП(б) ның Саба райкомы парткабинеты эшендә шактый уңышлар бар. Парткабинет марксизм-ленинизм классикларының әсәрләре белән тулысынча тәэмин ителгән. „ВКП(б) тарихының кыскача курсы" ның һәрбер бүлеге буенча альбомнар җитәрлек, һәр бүлеккә карата аерым витрина оештырылды. Партиянең XVIII нче съезды һәм өченче бишьеллык план буенча альбомнар, күргәзмә пособиеләр булдырылды. „Пропагандист", „Спутник агитатора", „Большевик", „Татарстан большевигы" журналлары һәм күп кенә башка журналлар алдырыла. Парткабинетта күп кенә сүзлекләр һәм белешмә материаллар бар.

ВКП(б) райкомы теоретик хәзерлекле 8 иптәшне консультант итеп билгеләде. Парткабинетта 1939 нчы елның март аеннан 1940 нчы елның январена кадәр 97 тапкыр групповой һәм индивидуаль консультация үткәрелде. 480 нән артык сорауга җавап бирелде. Консультантлардан Петров, Хәйруллин һәм Исламов иптәшләр аеруча яхшы эшлиләр.

Шуның белән бергә, консультацияләрне оештыруда парткабинетның күп кенә җитешсезлекләре дә бар әле. Парткабинетның эш планы партиянең башлангыч оешмаларына вактында җиткерелми. Шул сәбәпле консультациягә йөрүче иптәшләр парткабинетта кайсы көнне, нинди темада һәм нәрсә буласын алдан белмиләр. Бу хәл консультациягә йөрүчеләрнең хәзерләнеп килүләренә комачаулый.

ВКП(б) райкомы парткабинетка консультантлар беркетсә дә, аларның эшләре белән кызыксынганы юк. Консультантлардан иптәш Фазлиев өч тапкыр консультацияне өзде, район газетасы редакторы иптәш Мөхәметшин бер тапкыр да консультация үткәргәне юк.

И. Гариф.

САЛКЫН КАРАШ НӘТИҖӘСЕ

ВКП(б) ның Буденный райкомы парткабинеты, партиянең тарихи XVIII нче съездыннан соң, үзенең эшен үзгәртеп коруда шактый уңышларга иреште. Бу, бигрәк тә, „ВКП(б) тарихының кыскача курсы"н үзлегеннән һәм түгәрәкләрдә өйрәнүчеләргә конкрет ярдәм күрсәтүдә ачык чагыла. „Кыскача курс"ны өйрәнүчеләр өчен парткабинет планы буенча район үзәгендә һәм урыннарда системалы рәвештә консультацияләр, лекцияләр үткәрелә. Аңлашылып җитмәгән тегe яки бу мәсьәләләр буенча парткабинетка мөраҗәгать итүчеләргә җаваплар бирелә, алар кирәкле материаллар белән тәэмин ителәләр.

Районда массаның белемгә, марксизм-ленинизм теориясе белән коралланууга булган омтылышы гаять зур. Консультацияләргә, лекцияләргә аларның зур кызыксыну белән йөрүләре һәм актив катнашулары моны ачык күрсәтә.

Ләкин ВКП(б) райкомының пропаганда һәм агитация бүлеге һәм парткабинет консультацияләрнең, лекцияләрнең һәм докладларның һәр вакыт яхшы хәзерлек белән үткәрелүенә тиешле әһәмият биреп җиткермиләр әле. Мәсәлән, „Ислам диненең килеп чыгуы" дигән темада район үзәге клубында доклад үткәрелде. Райком тарафыннан билгеләнгән докладчы, урта мәктәпнең тарих укытучысы иптәш Максудова докладка яхшы хәзерлек белән килде. Ләкин, клуб бик салкын иде. Доклад тыңларга дип башта 150 гә якын кеше килгән булса да, соңыннан бары 40—50 кеше калды. Аннары докладның буласы шул көнне генә билгеле булды. Шуңа күрә дә бер генә кеше дә алдан хәзерләнеп килә алмады.

Болар барсы да парткабинетның һәм беренче чиратта аның мөдире иптәш Һадиевның докладны үткәрүгә тиешле әһәмият биреп җиткермәве турында сөйлиләр.

Яфизов.

ҮРНӘКЛЕ АГИТАТОР

Инженер иптәш Куликовский 3 нче мех фабрикасында (Казан) әле берничә ай гына эшләвенә карамастан, үзен яхшы агитатор итеп таныта алды.

Агитатор Куликовскийның беседалары һәр вакыт җанлы һәм кызыклы була. Чөнки ул үткән беседалардагы материалларны чираттагы тема белән оста итеп бәйли белә. Беседа вактында күргәзмә материаллардан, география картасыннан киң куллана.

Иптәш Сталинга 60 яшь тулу уңае белән, иптәш Сталинның тормышы турында 5 беседа, Лениннең тормышы турында 4 беседа үткәрде һәм фабрика күләмендә бу турыда ике доклад ясады. Иптәш Куликовскийның беседа өчен алган темалары күп: Кызыл Армиянең җиңүләре, Советлар Союзы Геройлары, „Седов" бозваткычы хәрәкәте, Япония белән СССР арасындагы мөнәсәбәт, Советлар Союзының уңышлары һ. б.

Эшчеләр иптәш Куликовскийның беседаларын көтеп алалар һәм аны яратып тыңлыйлар. Агитатор буларак, иптәш Куликовский „Большевик", „Молодой большевик" журналларын, үзәк һәм өлкә газеталарын системалы рәвештә укып бара. Беседаларга нык хәзерләнеп килә.

А. Таһиров.

Надежда Константиновна Крупская

(ҮЛҮЕНӘ БЕР ЕЛ ТУЛУ УҢАЕ БЕЛӘН)

Халыкның турылыклы кызы, Владимир Ильич Лениннең көрәштәше һәм юлдашы Надежда Константиновна Крупскаяның үлүенә бүген бер ел тулды.

Надежда Константиновна 1869 нчы елның 26 нчы февралендә Петербургда, ярлы интеллигент семьясендә туа. Ул шул замандагы алдынгы рус җәмәгатьчелеге даирәләреннән булган атасын мәхәббәт белән еш кына искә ала иде. Крупская революционерлар арасында тәрбияләнгәнлектән анарда яштән үк халыкка мәхәббәт хисе, аның азатлыгы өчен көрәш омтылышы туа.

Надежда Константиновна яштән үк революцион юлга баса. 1890 нчы елны ул Маркс һәм Энгельс әсәрләрен өйрәнү түгәрәгенә керә һәм шул ук вакытта Петербург студентлары түгәрәгенә җитәкчелек итә башлый. 1891 нче елны ул Шлиссельбург трактында эшчеләр өчен оештырылган беренче якшәмбе мәктәбенә укытучы булып керә һәм анда 5 ел буена, 1896 нчы елны кулга алынганга кадәр эшли.

1893 нче елны Петербургка В. И. Ленин килә. Ленин җитәкчелеге астында марксистик түгәрәкләр башка характер алалар. Эшчеләр белән элемтә ныгый, революцион пропаганда киңәя. Надежда Константиновна бер түгәрәктә Ленин белән очраша һәм аңа нык ярдәм итә башлый. Шул вакыттан башлап аларда ныклы дуслык башлана.

1895 нче елны Ленин җитәкчелегендә „Эшчеләр сыйныфын азат итү өчен көрәш союзы" төзелә. Надежда Константиновна аның эшендә актив катнаша.

1895 нче елның декабрендә бөтен үзәк группа белән берлектә Ленин кулга алынып Себергә сөрелә. Петербург текстильчеләренең гомуми забастовкасыннан соң 1896 нчы елны Надежда Константиновна да кулга алына. Ул 7 ай буена төрмәдә утыра, аннары 3 елга Уфа губернасына сөргенгә хөкем ителә. Үзенең соравы буенча ул Ленин сөрелгән урынга—Шушенское авылына җибәрелә. Бу сөргеннең авыр көннәре турында „Туганнарга хатлар" да күп язылган. Бу хатларда Владимир Ильич һәм Надежда Константиновна үзләренең дуслык белән җылытылган, иҗад хезмәте белән тулы булган бергәлек тормышларының беренче еллары турында язалар.

Лениннең сөргенен срогы тулганда, Надежда Константиновна әле тагын бер ел сөргендә булырга тиеш иде һәм ул сөрген срогын тутырырга Уфага китә.

1901 нче елны ул инде Мюнхенгә бара. Бу вакытта Ленин дә шунда була. Надежда Константиновна „Исрка" газетасы редакциясенең секретаре була. Россия белән революцион элемтә оештыру буенча аңа гаять зур эш йөкләнә. Партиянең бу заданиесен Надежда Константиновна партиянең II нче съездына хәзерлек чорында „Искра" редакциясендә дә, III нче съездга хәзерлек чорында „Вперед" газетасында да үти. Бөтен оештыру эше — комитетлар белән элемтә, иптәшләр белән очрашу һәм аларны урыннарга җибәрү, көчләрне урнаштыру, редакциядә, II нче һәм III нче съездда секретарьлык хезмәтләре — болар барсы да Надежда Константиновнага йөкләтелә.

Халык мәгарифе мәсьәләләре белән нык кызыксынып, Надежда Константиновна чит илләрдә бу эшнең куелышын өйрәнә.

1905 нче ел. Ленин белән берлектә Петербургка кайтып, Надежда Константиновна, партия Үзәк Комитеты секретаре буларак, яңа энергия белән революцион эш алып бара. Ул Таммерфорс конференциясендә катнаша һәм анда беренче тапкыр Сталин белән очраша. Декабрь восстаниесе бастырылганнан соң канлы террор чоры башлана. Ленин белән Крупская Финляндиягә күчәләр һәм 1907 нче елны яңадан чит илләргә чыгып китәләр.

Ул көннәрдә, патша Россиясендә рәхимсез реакция хөкем сөргән вакытта, Ленин, большевиклар партия сафларында вак буржуаз тайпылуларга каршы, ликвидаторларга һәм отзовистларга каршы көрәш алып бардылар. Надежда Константиновна бу көрәштә актив катнаша. Ул, Россиядән килгән эшчеләр өчен Париж янында Лонжюмода Ленин тарафыннан оештырылган партия мәктәбендә эшли.

1912 нче елгы Прага конференциясеннән соң Ленин һәм Надежда Константиновна Россиягә якынрак булу өчен Краковка күчәләр. Яңа революцион күтәренкелек башлану партиянең эшенә зур җанлану кертә. Россия белән язышу көчәя, аннан эшчеләр килү ешая, „Правда" газетасы белән, дума фракциясе белән ныклы элемтә урнаштырыла. Элекке кебек үк, бөтен оештыру эше Надежда Константиновнага йөкләтелә.

Бөтен дөнья күләмендә империалистик сугыш башлана. Бу елларда бары тик большевикларгына интернационализм принципларына турылыклы булып калдылар һәм хезмәт ияләрен сугышка каршы кискен көрәш алып барырга чакырдылар. Большевикларның 1915 нче елны булган Берн киңәшмәсендә Ленин империалистик сугышка карата большевистик тактика принципларын ачык итеп аңлата һәм чит илләрдәге группаларны туплау һәм халыкара элемтәләрне ныгыту өчен көрәшне җәелдерә.

Лениннең турылыклы көрәштәше—Надежда Константиновна большевикларның империализмга каршы көрәшләрендә актив катнаша. Шул ук вакытта ул „Халык мәгарифе һәм демократия" дигән китабын хәзерли.

Февраль революциясеннән соң, Россиягә кайткач, Надежда Константиновна Үзәк Комитет секретариатында эшли һәм Выборг районы думасына сайлана.

Июль көннәреннән соң Ленин подпольегә качарга мәҗбүр булгач, Надежда Константиновна, крестьян хатыны булып киенеп, Владимир Ильич янына бара һәм аңа барлык вакыйгаләрне белдереп тора. Ул партиянең VI нчы съезды эшләрендә катнаша. Бу съездга иптәш Сталин җитәкчелек итә.

Октябрь көннәрендә иптәш Крупская Смольныйда һәм партиянең Выборг комитетында эшли. Мәгариф Халык Комиссариаты оештырылуның беренче көненнән үк ул Наркомпрос коллегиясенең члены итеп билгеләнә.

1929 нчы елдан башлап Надежда Константиновна Мәгариф Халык Комиссарының урынбасары булып эшли һәм политик агарту эшләренә җитәкчелек итә, хатын-кызларга, комсомолецларга һәм пионерларга аеруча игътибар бирә.

Надежда Константиновна Союзыбызның барлык почмакларыннан көн саен уннарча хатлар ала. Ул аларның барсына да кирәкле сүзләр таба, кулыннан килгәнчә ярдәм итә.

Үзенең соңгы көннәренә кадәр Надежда Константиновна Ленин—Сталин партиясе интереслары белән, халык интереслары белән яшәде. Халык аны бердәм рәвештә СССР Верховный Советына депутат итеп сайлады.

Надежда Константиновна үз Ватанын ярата иде. Эшчеләр сыйнфына хиянәт итүчеләргә карата, Ленин—Сталин эшенә каршы көрәшүчеләргә карата ул совет халкының чиксез нәфрәте турында күп тапкырлар сөйләде. Аның түбәндәге сүзләре хәтердә нык саклана: „Троцкичы - бухаринчы шпионнарга һәм диверсантларга карата халкыбыз тирән нәфрәт һәм чиркану белдерә. Бездә дошманнарга карата башка төрле хис булырга да мөмкин түгел".

Халкыбызның турылыклы кызы, ялкынлы патриотка Надежда Константиновна үзенең бөтен көчен Ватаныбызга, хезмәт ияләрен азат итү өчен көрәшкә бирде.

Надежда Константиновна балаларга коммунистик тәрбия бирү турында, хатын-кызларны азат итү турында, халык мәгарифе турында, көтепханә эше һәм үзлегеңнән белем алу турында күп кенә китаплар язды, ленинизм буенча, Ленин идеяләрен масса арасында популярләштерү буенча күп мәкаләләр язды.

Надежда Константиновна Ленин турында гадәттән тыш җылылык белән сугарылган истәлекләр язды. Бу истәлекләр бөтен дөньядагы барлык халыкларның диярлек телләренә тәрҗемә ителде.

Надежда Константиновна Лениннең күптәнге уйларын тормышка ашыруга кадәр—илебездә социализм төзүгә кадәр яшәде. Лениннең безнең көннәргә кадәр яши алмаганлыгы турында, илебезнең ничек үскәнлеген, ныгыганлыгын һәм чәчәк атканлыгын аның күрә алмаганлыгы турында ул тирән әрнү белән сөйли иде. Культураның үсүе, илнең индустрияләшүе һәм авылның коллективлашуы аны шатландырды. Ленин эшен даһиларча дәвам иттерүче бөек Сталин җитәкчелегендә ирешелгән шушы уңышлар турында ул бөек горурлык белән сөйләде.

Надежда Константиновна бик җидди авыру иде. Ләкин ул туктаусыз эшләде, аның иҗади планнары зур иде. Аның көннәре санаулы дигән уйны бер кем дә уйлап та карамады. Бу турыда ул үзе башкалардан да азрак уйлый иде.

Ленин—Сталин партиясенең турылыклы члены, коммунизм өчен ялкынлы көрәшче—Надежда Константиновнаның якты образы халкыбызның, бөтен дөнья хезмәт ияләренең хәтерендә мәңге сакланыр.

М. Эссен.

ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ ХӘЗЕРЛЕК

ОРЛЫК БЕЛӘН ҮЗАРА ЯРДӘМ

Кукмара районы колхозлары арасында орлык белән үзара ярдәмләшү җәелде. „Победа" колхозы членнарының җыелышы „Труженик" колхозына 130 центнер, „Пчеловод" колхозы „Октябрь" колхозына 25 центнер орлык бирергә карар бирде.

Акташ районы колхозлары Теләче районы колхозларының чәчүлек орлык белән үзара социалистик ярдәм оештыру турындагы инициативасын яхшы каршыладылар. „Долина" колхозының членнары, колхозчы иптәш Тимаев тәкъдиме буенча, „Красный Строитель" колхозына бурычка 60 центнер орлык бирү турында карар чыгардылар. „Новый путь" колхозы „Верный путь" колхозына 47 центнер бодай, 40 центнер солы, 22 центнер карабодай орлыгы, „Красная заря" колхозы „Смычка" колхозына 46 центнер концентрат фураж бурычка бирәләр.

Дәүләки авыл советының „Яңа юл" колхозы, Апас райсоветы депутатларыннан Гафият Шәйхулов һәм Хәнәфи Сафин иптәшләрнең инициативасы буенча, үзара социалистик ярдәм тәртибендә Пушкин исемендәге колхозга 180 центнер сортлы орлык бирергә булды. Шул ук теләк белән „25 Октября" колхозы 400 центнердан артыграк, Ворошилов исемендәге колхоз 200 центнер орлык бүлеп куйды. (ТатТАСС).

ЯХШЫ БАШЛАНГЫЧ

Колхозларда иген уңышын күтәрү—кырчылык бригадаларының һәм аларга хезмәт күрсәтүче трактор бригадаларының уртак бурычы. Шуңа күрә дә трактор бригадасы белән кырчылык бригадасы эшен бергә бәйләп алып бару, үзара ярышып эшләү уңышларга ирешүдә бик әһәмиятле чара булып тора. Йөзпотчылар хәрәкәтенең инициаторлары, Сталинград өлкәсе бригадирлары Гуров һәм Козленков иптәшләр нак әнә шулай, трактор бригадасы белән кырчылык бригадасы арасында эшне бергә бәйләп алып бару аркасында уңышларга ирештеләр.

Гуров һәм Козленков иптәшләрнең бу эш үрнәкләрен безнең республикабыздагы бригадирлар да үзләренә күчерә башладылар. Мәсәлән, Актаныш районы, Актанышбаш колхозының беренче бригада бригадиры Рокия Ханова белән шул ук МТС ның 6 нчы бригада бригадиры Әгләмов иптәшләр һәм Кайбыч районы Фрунзе исемендәге колхозның 2 нче бригада бригадиры Шәфигуллин белән Мөрәле МТС ының хатын-кыз тракторчылар бригадасы бригадиры Сибгатуллин иптәшләр бу эшне башлап җибәрүче булдылар. Алар эшне бергәләп, уртак план белән алып бару турында киңәшеп үзара социалистик ярыш договорлары төзеделәр.

Ярыш договорлары буенча иптәш Ханова бригадасы бригадада бөртекле культураларның һәр гектарыннан кимендә 120 пот иген уңышы алуга ирешүне, ә иптәш Әгләмов бригадасы һәрбер „СТЗ" тракторы белән кимендә 1.500 гектар эшләүне йөкләмә итеп алдылар.

Иптәш Шәфигуллин бригадасы бөртекле культураларның һәр гектарыннан кимендә 100 пот иген уңышы алуга ирешүне, ә бригадир иптәш Сибгатуллин барлык эшләрне дә агротехника кагыйдәләренә төгәл туры китереп үтәүне йөкләмә итеп алдылар.

Ханова һәм Әгләмов, Шәфигуллин һәм Сибгатуллин иптәшләрнең бу эшләре трактор бригадалары белән кырчылык бригадалары арасында эшне бергә бәйләп алып бару өчен, һич шиксез, яхшы башлангыч булып тора. Республикабыздагы башка бригадирлар да бу иптәшләрдән үрнәк алырга тиешләр.

ҮРНӘК ЭШ

Сталин исемендәге совхозда (Теләче районы) эшче һәм хезмәткәрләрнең семья членнары производствода актив катнашалар. Совхоздагы партоешма шушы көннәрдә йорт хозяйкаларының җыелышын үткәрде. Җыелышка 50 кеше катнашты. Бу җыелышта язгы чәчүгә хәзерлек һәм аны үткәрүдә йорт хозяйкаларының бурычлары турында доклад тыңланды.

Тракторчыларның, комбайнчыларның һәм белгечләрнең хатыннары быел совхоз производствосында кимендә 2 шәр йөз хезмәт көне эшләргә йөкләмә алдылар. Совхоз производствосында үткән елны актив катнашкан Галия иптәш Якупова болай диде:

— Мин хәзер тракторны һәм башка машиналарны тырышып өйрәнәм. Быел ирем комбайнчы булып эшләячәк. Мин аның агрегатында комбайнчының ярдәмчесе булып эшләргә хәзерләнәм.

Комбайнчы хатыны иптәш Козлова да шул ук фикерне әйтте. Совхоздагы белгечләрнең хатыннары Касимова һәм Габделхакова иптәшләр үзләре эшләячәк участкыларда һәр гектардан 650 центнер чөгендер уңышы алуга ирешү турында йөкләмә алдылар.

К. Ракипов.

Күргәзмәгә катнашуга кандидатлар

Норлат районы колхозларыннан һәм авыл хуҗалыгы алдынгыларыннан 1940 нчы елда Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә катнашуны сорап 72 гариза бирелде. Шулардан: бөртекле культуралар һәм терлекчелек буенча 22 колхоз, механизатор кадрлар һәм терлекчелек алдынгыларыннан 27 кеше, колхозларның учет работниклары алдынгыларыннан 9 кеше күргәзмәгә катнашуга кандидат итеп расландылар.

Күргәзмәгә кандидат итеп расланучылардан „Красный Дол" колхозы соңгы өч елда һәр гектардан уртача 14,26 центнер уңыш алды. Үткән ел күргәзмәгә катнашкан Киров исемендәге колхоз 1939 нчы елны аерым участкыларда һәр гектардан уртача 421 центнер кишер уңышы алды.

Күргәзмәгә кандидат итеп расланган экспонентлар быел тагын да югарырак уңышларны яулап алу өчен көрәшәләр.

М. Гыйсмәтуллин.

Алдынгыларның тәҗрибәләрен башкаларга да күчерергә

(Хәбәрче хатлары буенча)

Хәбәрче иптәш Никитин Саба районының „Үрнәк" колхозында язгы чәчүгә хәзерлек эшләренең барышы турындагы хатында болай дип яза:

— „Үрнәк" колхозы членнары язгы чәчүгә зур оешканлык белән хәзерләнәләр. Йөзпотчылар ярышына кушылу колхозчыларда яңа дәрт тудырды. Колхозның чәчү орлыклары яхшы сыйфатлы итеп чистартылды һәм коры урында саклана. Авыл хуҗалыгы инвентарьларына ремонт ясау төгәлләнде. Кышкы агротехника чараларын үткәрү һәм җирле ашламалар хәзерләү эшләре кызу темп белән бара. Басуга тирес чыгаруда В. Максимова, М. Зайцева һәм Ф. Васюкина иптәшләр норманы 130—150 процент үтиләр.

Колхозчылар атларны тәрбияләүгә нык игтибар бирәләр. Ат караучылардан М. Семенова, Ф. Егорова иптәшләр аеруча тырышып эшлиләр. Атларның көрлеге яхшы. „Үрнәк" колхозы һәр гектардан кимендә 100 пот уңыш алу өчен „Кызыл Тау №2" колхозы белән ярыша.

* * *

Актаныш районыннан иптәш Хаҗиев болай дип хәбәр итә:

— Һәр гектардан 100 пот уңыш үзеннән үзе килми, аны яулап алырга кирәк. Безнең Куйбышев исемендәге колхоз членнары моны үз тәҗрибәләрендә беләләр. Язгы чәчүне уңышлы үткәрү югары уңыш өчен көрәштә хәл иткеч чара. Без язгы чәчүгә үрнәк булырлык итеп хәзерләнү өчен бөтен мөмкинлекләрдән файдаланабыз. Нәтиҗәләр начар түгел: чәчкечләр һәм авыл хуҗалыгы инвентаре, ат сбруйлары тулы хәзерлектә. Орлыклар тиешле кондициягә җиткерелгән. Кар тоту, басуга тирес чыгару планы 100 процент үтәлде.

Хәбәрче иптәш Шиһапов „Ялан", „Шахтер" һәм „Уракчы" колхозларында (Чистай районы) гектардан йөз пот уңыш алу өчен көрәшнең көннән-көн киң колач ала баруын, колхозчыларның чәчүгә бердәм хәзерләнүләрен күрсәтеп яза.

Алдынгы колхозлар белән бер рәттән, чәчүгә хәзерлекне үз агымына куючы, алган йөкләмәләре өчен үзләрен җаваплы санамаучы колхозлар да бар әле.

Мәсәлән, иптәш Садыйков язган хәбәрдә түбәндәгеләрне укыйбыз:

— Апас районының „Шушма", „Комбайн", „Радио" колхозларында һәм Буденный, Ворошилов исемендәгеколхозларда язгы чәчүгә хәзерлекнең барышы һич тә канәгатьләнерлек түгел. Кышкы агротехника чаралары планы үтәлми. „Комбайн" колхозында кар тоту планы бары 7 процент, басуга тирес чыгару—27 процент, көл җыю планы 20 процент кына үтәлгән. Ворошилов исемендәге колхозда да шул ук хәл. „Шушма" колхозында чәчүлек орлыкларны чистарту хәзергә кадәр башланмаган.

Шундый ук гамьсезлек фактлары Апас районының башка колхозларында да бар.

— „Мәгариф" колхозында,—ди хәбәрче иптәш Камалов,—язгы чәчүгә хәзерлек тирән өзеклектә. Авыл хуҗалыгы инвентарена ремонт ясау башланмаган диярлек. Шушы вакытка кадәр бары 5 кенә сабанга ремонт ясалган. Җирле ашламалар җыю планының өчтән бер өлеше дә үтәлмәгән.

Иптәш Камалов бигрәк тә Чүри-Бураш МТС ында эшнең акырын баруын күрсәтә. Биредә тракторларның дүрттән бер өлеше генә ремонтланган. 7 тракторга ясалган ремонтның сыйфаты начар. Эшчеләр арасында социалистик ярыш йомшак. Шуңа күрә көнлек эш нормалары үтәлми һ. б.

Югарыда китерелгән фактлар аерым урыннарда колхоз һәм МТС җитәкчеләре тарафыннан язгы кыр эшләренә хәзерлеккә тиешле җитәкчелекнең булмавын күрсәтәләр.

Җир органнарының бурычы—колхозчыларга чәчүгә иң яхшы итеп хәзерләнү өчен, алган йөкләмәләрен төгәл һәм арттырып үтәү өчен ярдәм итүдән, алдынгы колхозларның эш тәҗрибәләрен уртаклашуны оештырудан һәм барлык колхозларда, совхозларда һәм МТС ларда Сталинчыл өченче бишьеллыкның өченче язына большевистик хәзерлекне тәэмин итүдән гыйбарәт.

Әлки МТМ ында. РӘСЕМДӘ: механика цехы бригадиры иптәш И. А. Бурмистров иптәш М. Уральскаяны строгаль станогында эшләргә өйрәтә. С. Чиколкин фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

Халыкара коммунистик хатын-кызлар көне— 8 нче Март алдыннан

ЗУР КӨЧ

Халыкара хатын - кызлар көне 8 нче Март якынлаша. Совет хатын-кызлары, Ватаныбызның тулы хокуклы, бәхетле һәм шатлыклы гражданнары бу көнне зур уңышлар белән каршылыйлар. Совет хатын-кызы дигән исем бөтен дөньяда горур яңгырый.

Совет хатын-кызы халык хуҗалыгының барлык тармакларында да актив катнаша. Ул дәүләт эшлеклесе, инженер-техник, укытучы, врач, фәнни работник. Ул паровоз машинисты, пароход капитаны. Ул данлы Кызыл Армиябезнең, Кызыл Флотыбызның актив ярдәмчесе — хәрби врач, хәрби летчик һәм башкалар.

Совет хатын-кызлары Сталин Конституциясе кояшы астында, бөек Ленин — Сталин партиясе җитәкчелегендә әнә шулай үсәләр, шулай күтәреләләр. Элек авыр һәм ят булып күренгән яңа эш төрләрен хатын-кызлар большевикларча үзләштерәләр. Соңгы елларда гына да хатын-кызлардан миллионнарча тракторчылар, шоферлар, паровоз машинистлары, сталеварлар, слесарьлар, токарьлар хәзерләнде һәм хәзерләнә. Безнең совет хатын-кызлары ирләрне теләсә нинди минутта алмаштырырга, бөек Ватан тынычлыгын күкрәк киереп сакларга һәр вакыт хәзер торалар.

В. И. Ленин исемендәге җитен комбинатының атаклы тукучысы, берьюлы дүрт туку станогында эшләүче, хөкүмәтебез тарафыннан „Аеруча хезмәт күрсәткән өчен" медале белән бүләкләнгән, Киров райсоветы депутаты иптәш А. Е. Иванова да илебездә үскән, чыныккан миллионнарның берсе. Хәзер иптәш Иванова яшьләрне тәрбияләү өлкәсендә зур эш алып бара. „Миндә өйрәнчек булып эшләүче иптәш Солтанова 8 нче Март бәйрәмен үз эше техникасын отличнога үзләштергән тукучы булып каршылаячак" ди иптәш Иванова.

Менә, комсомолка иптәш Е. М. Жиркова. Ул фрезер станогында эшләүне комбинатта иң беренче булып үзләштерде. Хәзер ул берьюлы ике фрезер станогында эшли. Көндәлек нормасын системалы рәвештә 180—200 процент итеп үти. Аның айлык хезмәт хакы 550—600 сумнан кимеми.

Бу комбинатта 19 нчы елын эшләүче Маһикамал апа Рәхмәтуллина исеме күпләргә билгеле. Ул монда күп эш төрләрен үтте. Башта өйрәнчек, ә соңыннан тукучы булды. 9 ел инде Маһикамал апа ФЗУ мәктәбендә инструктор булып эшли. Туку эше буенча тупланган бай тәҗрибәсен яшьләргә өйрәтә. Яшьләрдән үзе кебек оста тукучылар хәзерли.

40 еллык хезмәт батыры, мактаулы ватерщица иптәш Горина хәзер ике станокка хезмәт күрсәтә. Үзенең көндәлек планын әледән-әле арттырып үти.

Алар күп. Алар комбинатта үсәләр һәм үсәләр. Алар рядовой эшчедән мастер, бригадир итеп күтәреләләр. Мәсәлән, иптәш Ногорнаяны алыйк. Ул инде хәзерлек цехының мастеры. Цехта оборона эше активисты. „Үз эшемне отличнога башкару белән бергә, 8 нче Мартка бүләк итеп, 10 кешене ПВХО значкистлары итеп хәзерләячәкмен", ди ул. Берьюлы дүрт туку станогында стахановча эшләүче Маюрова һәм Кучумова иптәшләр дә үзләренең белем дәрәҗәләрен күтәрү өстендә тырышып эшлиләр, якын арада урта белем алу өчен көрәшәләр. Алар комбинат янында оештырылган стахановчылар мәктәбенең отличниклары.

— 3—4 станокта эшләүне большевикларча үзләштерергә, яңа нормаларны арттырып үтәргә, иң кимендә ике-өч оборона значокларына нормалар тапшырырга, 8 нче Март бәйрәмен яңадан-яңа уңышлар белән каршыларга— җитен комбинатында эшләүче алдынгы хатын-кызларның бердәм омтылышы әнә шундый.

Ким Биков.

Эшлекле хәзерлек

Киез итек-фетр фабрикасы (Казан) хатын-кызлары 8 нче Март бәйрәменә эшлекле хәзерлек алып баралар. Производствода эшләүче хатын-кызлар үзләренә бирелгән нормаларны арттырып үтәү өчен көрәшәләр. Комиссарова, Танкиева, Рәхимҗанова иптәшләр социалистик ярышта алган йөкләмәләрен намус белән үтиләр. Алар норма үтәлешен 130—140 проценттан киметмиләр.

Фелец бүлеге начальнигы, Сталин район советы депутаты иптәш Изосимова яшь эшчеләрне тәрбияләүдә, аларны квалификацияле эшкә өйрәтүдә зур инициатива күрсәтә. Мәсәлән, фабриканың бу бүлегендә әле 4 нче ай гына эшләүче Гәрәева иптәш Изосимова тырышлыгы белән берьюлы ике фелец машинасында эшләүне үзләштерде. Хәзер ул үз нормасын 200 проценттан арттырып үти.

Хәзер бездә беседалар үткәрү, кычкырып газеталар уку эше дә яхшыртыла. Логинова һәм Галиев иптәшләр бу өлкәдә аеруча тырышып эшлиләр. *Х. Галиев.*

ТАТНАРКОМЗЕМ ИГТИБАРЫНА

Шәһәр тирәсендәге бәрәңге-яшелчә зоналарында, шулай ук яшелчәчелек белән шөгыльләнүче Алабуга, Чистай һәм башка бик күп кенә районнарның парник хуҗалыкларында 1940 нчы елда яшелчә үстерүгә хәзерлек эшләре чиктән тыш начар оештырылган.

Быел Алабуга районы колхозларында 16 мең рам парник булдырылырга, шулардан 8 меңендә иртә өлгерә торган яшелчәләр үстерелергә тиеш. Ләкин район оешмалары бу эшкә гафу ителмәслек начар хәзерләнәләр. Бүгенге көндә районда бары 7.700 рам парник эшкә яраклы хәлгә китерелгән. Ә калганнарын ремонтлау турында һич кем кайгыртмый. Рамнарга пыяла кую эшенә бөтенләй керешелмәгән дә. 11 мең данә мата урнына әле бары 2 мең данә мата хәзерләнгән. Парниклар хуҗалыгына беркетелгән участкылар җитәрлек түгел, булганнары да көздән чистартылып, хәзерләнеп куелмаганнар.

Шәһәр зонасына керә торган районнарда да яшелчә үстерүгә хәзерлек эше бик начар оештырылган. Бу районнарда узган ел яңадан 20 мең рам парник һәм 32 теплица төзелергә тиеш иде. Ләкин төзелеш планы хурлыклы рәвештә өзелде. Бүгенге көндә төзелеп беткән бары бер теплица бар. Калганнарының кайчан төзелеп бетәчәге турында берәү дә белми. Ә парниклар турында мәгълүматлар бөтенләй юк. Район җир бүлекләре колхозларда булган парникларның дөрес санын әйтә алмыйлар. Мәсәлән, Юдино район җир бүлеге узган ел 1.967 яңа парник төзелү турында мәгълүмат бирде. Ә фактта бу районда бары 610 рам парник төзелгән.

Югары Ослан районында парниклар хуҗалыгы белән бер кемдә җитәкчелек итми. Биредә парниклар хуҗалыгы онытылган бер участкы булып тора. Район җир бүлеге мөдире иптәш Оришин яшелчә үстерү мәсьәләсе белән бөтенләй шөгыльләнми. Шушыларның нәтиҗәсе буларак бу районда 5.490 рам парник урнына, әле бары 3.000 рам парник хәзерләнгән. Маталар җитәрлек түгел. Моннан бер ел элек 5 урында теплицалар төзү эшенә керешелгән булса да, әле аларның берсе дә төзелеп беткәне юк.

Юдино районында 6 мең данә мата урнына бары 190 данә мата хәзерләнгән. Рамнарны төзәтү һәм пыяла кую эшләре акырын бара. Парниклар хуҗалыгы участкыларының өчтән бер өлеше генә яшелчә утырту өчен яраклы. 1939 нчы елның 1 нче ноябренә төзелеп бетәргә тиеш булган 4 теплицаның әле дә булса төзелеп беткәне юк.

Лаеш, Дөбъяз, Арча, Питрәч районнарында да шундый ук хәл. Парникларда һәм теплицаларда эшләү өчен бер генә районда да махсус звенолар оештырылмаган. Парникларга тирес чыгару эше тирән өзеклектә.

Селхозснаб парниклар өчен кирәк булган пыяланы узган ел ук хәзерләп куярга һәм колхозларны үз вактында пыяла белән тәэмин итәргә тиеш иде. Ләкин селхозснаб җитәкчеләренең үз эшләренә салкын караулары аркасында пыялалар вактында кайтарылмадылар. Ә хәзер бу җитәкчеләр „пыяла кайтару өчен вагон бирмиләр" дигән сылтау тапканнар.

Нәтиҗә ачык. Шәһәр тирәсендә бәрәңге-яшелчә зоналары булдыру эше өзелү куркынычы алдында тора. Ләкин Наркомзем җитәкчеләре яшелчәчелек өлкәсендәге бу зур җитешсезлекләргә карата килешүчәнлек күрсәтәләр. Хәзерге көндә Наркомземда яшелчәчелек мәсьәләсе белән берәү дә шөгыльләнми диярлек.

Быел колхозларда яшелчә үстерү эшен уңышлы башкарып чыгу өчен барлык парникларны һәм теплицаларны ашыгыч рәвештә төзәтеп бетерергә, яңаларны төзү эшен тизләтергә, маталарны, орлыкларны алдан ук хәзерләп куярга һәм кичекмәстән тирес чыгару эшенә керешергә кирәк.

Җамалов.

Татнаркомзем агрономы.

ТРАКТОРЛАРГА РЕМОНТНЫҢ СЫЙФАТЫН ЯХШЫРТЫРГА

Татарстандагы МТС ларда тракторларга ремонт ясау эше бик акрын бара. 20 нче февральгә план бары 61,1 процент үтәлгән. ЧТЗ һәм СТЗ—НАТИ тракторларын ремонтлау бигрәк тә акрын бара.

Кайбер МТС ларның директорлары һәм өлкән механиклары ремонтның югары сыйфатлы булуына игтибар бирмиләр. Мәсәлән, Октябрь МТС ында (директоры иптәш Беляев) дирекция кабул итеп алган биш тракторның бишесе дә яраксыз табылган һәм алар яңадан ремонтка бирелгәннәр.

Үзәк МТС ында да (директоры Газизов, өлкән механик Ильин иптәшләр) ремонттан чыккан тракторларда күп кенә җитешсезлекләр бар. 27 нче номерлы тракторда маслоотражатель юк, һава чистарткыч пычрак, һава һәм су шланглары тимер чыбык белән бәйләп куелганнар; 11 нче номерлы тракторга фильтр куелмаган, моторның эшләве тәртипкә салынмаган.

Иске Писмән МТС ында (директоры Демидов, өлкән механик Алаев иптәшләр) ремонттан чыккан һәм дирекция тарафыннан кабул итеп алынган 6 тракторны Наркомзем вәкиле яраксыз дип тапкан, алар яңадан ремонтка бирелгәннәр.

Кайбер МТМ нарда моторларга ясалган ремонтның да сыйфаты канәгатьләнерлек түгел. Мәсәлән, Тәтеш МТМ ның (директоры Тимофеев һәм өлкән механигы Заболотнов иптәшләр) Тәтеш МТС ына тапшырган 23 нче номерлы трактор моторының алгы банкасын ныгыту болты чүпрәк белән генә тыгызлап утыртылган булган.

Олы Кариле МТС ыннан җибәрелгән моторларга зур диаметрлы шпилькалар куярга кирәк иде, ә Тәтеш МТМ ы аңа нормаль шпилькалар куйган, алар мотор эшли башлау белән коелып төшкәннәр. Тәтеш МТС ының заказы буенча СТЗ—НАТИ тракторы өчен хәзерләнгән 43 данә шайба яраксыз булып чыккан.

Казан, Чистай, Арча һәм Тәтеш МТМ нарының директорлары һәм өлкән механиклары моторларга ремонт ясау буенча билгеләнгән кагыйдәне бозалар. Ремонттан чыккан моторлар куәтлелек буенча һәм ягулык расходы ягыннан тикшерелергә һәм сынап каралырга, терсәкле валның әйләнеше мастерскойда ук тәртипкә китерелергә тиеш. Ә югарыда әйтелгән МТМ нарда моны үтәмиләр.

Карбюратор двигательләре үзләренең карбюраторлары белән, дизельләр үзләренең ягулык аппаратуралары белән сынап каралырга тиеш. Ләкин мастерскойлар бу кагыйдәне үтәмиләр. Ә МТС директорлары һәм өлкән механиклары МТМ нардан моны үтәүне таләп итмиләр.

Хәзер клапоннар булмагалыктан СХТЗ моторларына ремонт ясауны тоткарлау фактлары бар. МТМ нарның Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә тупланган тәҗрибәләре СХТЗ моторлары клапоннарының тарелкасын 52 миллиметрга кадәр кечрәйтү мөмкинлеген күрсәтте. Шуңа карамастан, аның көче кимеми һәм ягулык артык тотылмый.

Димәк, яраксызга чыгарылган клапоннардан файдаланырга мөмкин, моның өчен шомарту юлы белән тарелканы 52 миллиметрга кадәр кечрәйтергә кирәк. Бу вакытта клапоннар өчен головка оясындагы бөҗраның эчке диаметры 44 миллиметр итеп билгеләнә. Шулай итеп, клапоннар җитешмәү кебек кыенлыклардан котылырга мөмкин.

Күргәзмәдә, моторны җыйганнан соң, аны эшләтүнең кызыклы һәм оригиналь ысулы күрсәтелде. Моның өчен кыйммәтле май урнына 2 процент эмульсол кушылган су кулланыла. Моторның частьләрен бу ысул белән чистарту шактый тиз үткәрелә. Суны моторның катерыннан агызганда катер эчендә калган барлык кечкенә металл кисәкләре су белән агып төшәләр.

Бу яңа ысул моторның эшләвен шактый җиңеләйтә һәм арзанайта. МТМ нарда бу ысулны кулланырга кирәк.

Иске запас частьләрне яңартуда һәм яңаларны хәзерләүдә МТМ һәм МТС директорлары һәм өлкән механиклары үзләрендәге мөмкинлекләрдән тулы файдаланмыйлар әле. Мәсәлән, мастерскойлардагы станоклар һәм җиһазлар бер-ике сменада гына файдаланылалар. МТМ директорлары һәм өлкән механиклары күп станокта эшләүне оештырмаганнар һәм эшчеләрне моңа тупламаганнар.

Хезмәтне дөрес оештырып, эчке мөмкинлекләрдән тулы файдаланганда МТС һәм МТМ нар машина-трактор паркына ремонт ясауны вактында һәм яхшы сыйфатлы итеп төгәлләүгә ирешерләр.

С. Резяпкин.

Татнаркомземның баш инженеры.

Чит илләрдә

ГИТЛЕР РЕЧЕ

БЕРЛИН, 25 февраль. (ТАСС). Германиянең информация бюросы Мюнхеннән Гитлер речененң текстын тапшыра. Түбәндә бу речь кыскартылган төстә бирелә. Речь Германиянең милләтче-социалистлар партиясе төзелүгә 20 ел тулуга багышланган тантаналы җыелышта, 24 нче февральдә кич белән сөйләнгән.

Гитлер үзенең речендә заманында Германиянең алданганлыгын, Вильсонның 14 пунктын, шушы пунктлар аркасында Германия халкының үзенең коралын ташлаганлыгын искә төшереп үтә. Гитлер болай ди: „Безне җиңмәделәр, Германия халкы алданган иде, ә аның дөньяны үзгәртеп кору мөмкинлегенә ышанычы какшатылган иде". Англиянең һәм Франциянең шул ук вакытта бөтен дөньяны һәм барыннан да элек Германия халкын алдаганлыкларына һәм бу алдауның нинди нәтиҗәләргә китергәнлегенә Гитлер тулы итеп туктала. Германияне бары тик тышкы формаль хәлләр генә какшаттылар. Ләкин Германия халкы какшамады. Ул 26 дәүләткә каршылык күрсәтеп, бөтен дөнья тарихында бөек эш эшләде. Бу дәүләтләр Германияне бары тик алдау юлы белән генә җиңә алган булырлар иде.

Без властька килгәч, коралланырга теләмәдек. Ләкин без моннан элек сугыш уты кабызган кешеләрнең безгә яңадан һөҗүм итәргә хәзерләнүләрен күрдек. Моңа җавап итеп мин дә коралланa башладым һәм Германия тарихында бер вакытта да булмаган дәрәҗәдә коралландым.

Милләтче-социалистлар җитәкчелегенең уңышларын күрсәтеп, Гитлер, хәзер инде гаят зур бина корылганлыкны, моны демократиянең дәүләт эшлекләләре дип аталган кешеләрнең уңышлары белән һич тә тиңләштерергә мөмкин түгеллекне әйтә. Бу кешеләр җир шарының зур өлешендә хөкем сөрәләр, ләкин аларның хәтта үз илләрендәге эшсезлекне бетерергә дә хәлләреннән килми. Шул ук булдыксызлар хәзер Европаны үзгәртеп кору турында сөйләнәләр.

Чемберлен әфәнде үзенә бөтен Һиндстан, бөтен Гарәбстан протест белдереп торганда речь сөйләп, безнең бөтен дөньяда Германия өстенлеген тормышка ашырырга тырышуыбызга каршы көч кулланырга тиешлеген белдерергә батырчылык итә. Ихтимал, мондый фразалар 1918 нче елны Германия халкына йогынты ясый алган булырлар иде, ләкин яңа Германиядә бу хәл бер кайчан да булмас.

Аннары Гитлер сүзендә дәвам итеп, Германиянең дәгъвалары бик кечкенә булганлыкны әйтә. Алар, беренчедән, Германиянең яшәвен тәэмин итүгә омтылудан гыйбарәт булдылар. Германия халкы үзенең яшәвен кисеп алуга юл куймас. Икенчедән, Германия үзенең колонияләрен, ягни Германиянең бөтен дөнья плутократиясе тарафыннан тартып алынган милкен кире кайтаруны таләп итте. Англия һәм Франция дәгъваларына чагыштырганда болар бик кечкенә дәгъвалар иде. Шуңа да карамастан, безнең бөтен дөнья сугышы чорындагы иске дошманнарыбыз яңадан күтәрелделәр. Ләкин хәзер инде аларга каршы Германиянең барлык кирәкле хәзерлекләрне бик нык итеп үткәргән һәм үз халкына карата үзенең бурычын тулысынча аңлаучы фронт солдаты чыкты.

Германиягә каршы блокаданың нәтиҗәсез икәнлеген әйткәннән соң, Гитлер, халыкара хәлнең шактый үзгәргәнлеген күрсәтә. Гитлер Италия белән дуслык турында искә ала. Аннары Гитлер Германия—Россия мөнәсәбәтләренең үзгәрүе турында искә төшереп үтә. Дошманнарның Россия белән Германия арасында сугыш кабызырга өметләнүләре җимерелде. Хәзер рус һәм герман режимы һәр ике халык өчен бик яхшы эш эшләделәр. Ләкин без Лондондагыларның борчылудан үзләренең нәчләрен йолкуларын бик яхшы беләбез. Япония дә шулай ук хәзер Германия дошманнары сафларында түгел, киресенчә, ул Германия белән бик дус. Бу өч зур дәүләт Германиягә карата яхшы нейтралитет саклыйлар.

Гитлер Германиянең кораллы көчләренең хәлнең киләчәктә тагын да үзгәрүенең билгесе икәнлеген күрсәтә. Бу көчләргә җитәкчелек итү һәм аларны тәэмин итү 1914 нче елга чагыштырганда шактый яхшырды. Польшага каршы поход моның буш фраза түгеллеген күрсәтте. Бу поход Лондонда һәм Парижда көтелгәнгә караганда тизрәк тәмам булды. Хәер, моны киләчәк тә күрсәтер әле.

Аннары Гитлер Германиянең экономик яктан гаят зур хәзерлекләрен күрсәтә. Хәзердә дә инде Германиянең хуҗалык нигезләрен гаят нык дип санарга мөмкин. Германия хуҗалык ягыннан да, сугыш ягыннан да җиңелмәслек.

Англиянең пропаганда ясарга маташуына тулысынча тукталып, Гитлер, бу пропаганданың бөтенләй нәтиҗәсез икәнлеген әйтә. Һәрбер башка халык кебек Германия халкының да яшәргә хокукы бар. Гитлер Германия дошманнарының хәзер моннан элек булган кебек сан ягыннан өстен түгеллекләрен һәм хәзерге вакытта Германия халкының сугыш ягыннан үзенең тарихында кайчан булганга караганда да күп яхшырак хәлдә икәнлеген аеруча күрсәтә. Германия халкының кол халык булып калуына язмыш ирек куймас. Бүген мин моңа тулысынча һәм, ихтимал, элеккедән дә күбрәк хокук белән ышанам. Башкача булырга мөмкин түгел: без җиңәргә тиешбез һәм шуңа күрә без җиңәрбез.

КИНО

„ДҮРТЕНЧЕ ПЕРИСКОП"

Ленфильм студиясе илебезнең хәзерге заман Хәрби Диңгез Флоты турында „Дүртенче перископ" картинасын чыгарып тагын да яңа уңыш казанды. Бу, Хәрби Диңгез Флотының куәтен күрсәтүче картиналарның берсе.

... Эскадраларның маневрлары бара. Халыкара хәл аеруча кискен булганлыктан, төрле хәлләрнең килеп чыгуы мөмкин. Маневрларга 3 су асты көймәсе катнаша. „Отважный" көймәсендә капитан булып Владимир Крайнев, ә „Спрут" көймәсендә капитан булып аның туганы—Григорий Крайнев хезмәт итәләр.

План буенча „Спрут" маневрларда катнашырга тиеш түгел. Аңа башка бурыч йөкләтелә. Маневр башланып күп тә үтми, каяндыр дүртенче көймә килеп чыга. „Отважный" командиры Владимир Крайнев бу хәлгә башта аптырап кала һәм сигнал бирә. Ләкин су асты көймәсе җавап бирми. Хәл авырлаша. Бу турыда мәсьәләне тиз һәм кискен рәвештә хәл итәргә кирәк. Дошман көймәсе булса, безнең линкорны батыруы мөмкин. Ә „Спрут" булса? Анда Григорий Крайнев...

„Отважный" да тревога бирелә. Бер минут вакыт эчендә билгесез көймә батырыла. Эпроичылар батырылган көймәне тикшереп, анда совет папирослары һәм чит ил гербы кадаган фуражка табалар.

Ләкин „Спрут" һаман юк. „Спрут" ны эзләү башлана. Картинаның икенче өлеше әнә шуңа багышлана. Штабта дошманның мәкерле планнары ачыла. Һәм, озак та үтми, „Отважный" моряклары „Спрут" ны табуга ирешәләр. Куркынычлы һәм җиддн шартларда геройларча көрәшеп җиңеп чыккан батыр командирлар—Владимир һәм Григорий Крайневлар очрашалар.

Данлыклы Кызыл флотыбызның зур адымнар белән тагын да алга атлавын, куәтен күрсәтүче бу картинаны тамашачы зур кызыксыну белән карый. Картина тулы чынбарлыкны күрсәтә.

Ләкин картинаның кимчелек яклары да юк түгел. „Отважный" көймәсенең комиссары Зотов образында бу кимчелек аеруча күренә. Кызыл Армиядә һәм флотта комиссар зур урын тота, билгеле. Ул сугышчыларны политик яктан тәрбияли, оператив мәсьәләләрне хәл иткәндә командирга ярдәм итә. Картинадагы комиссарлар Зотов һәм Струнко („Спрут" көймәсенең комиссары) йомшак бирелгәннәр.

Режиссер В. Эйсьмонт, сценаристлар Г. Блауштейн һәм Г. Венецианов куәтле флот турында, аның батыр сугышчылары һәм командирлары турында бик файдалы фильм эшләгәннәр. Бу картинаның хәзерге вакытта—фин халкын ак бандитлар—Маннергеймнар тырнагыннан коткару өчен Балтыйк флотының героик көрәш алып барган көннәрендә экранга чыгуы аеруча әһәмиятле.

М. Яхин.

Талантлы укучыларга персональ стипендияләр

Татарстан Халык Комиссарлары Советы, Казан Музыка училищесенең 35 еллык юбилее уңае белән, училищенең аеруча талантлы укучыларына билгеләү өчен 18 мең сум акча җибәргән иде. Бу суммадан 12 укучыга персональ стипендияләр билгеләнде. Персональ стипендия алучыларның барсы да уку отличниклары. Алар арасында яшь композиторлардан—Шәмсеттинов (II нче курс), Вәлиуллин (V нче курс), Степан Григорьев (IV нче курс), скрипка классыннан Павлова (IV нче курс) һәм Әнвәр Бакиров (III нче курс), виолончель классыннан Халитов (III нче курс), Абдуллин (I нче курс), Таймасов (II нче курс), флейта классыннан Малюгин (IV нче курс), фортепиано классыннан Алексей Григорьев (IV нче курс), халык инструментлары классыннан Фәйзуллин, җыр классыннан Шәмсеттинова иптәшләр бар.

Казан мехкомбинаты янындагы медицина сестралары курсында. РӘСЕМДӘ (сулдан): уку отличникларыннан Л. Н. Сумина, М. Н. Абдюшева, Е. И. Щербакова һәм О. А. Сорокина иптәшләр анатомия дәресендә.
А. Усольцев фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

Күңелле очрашу

Шушы араларда татар совет язучыларыннан һәм шагыйрьләреннән М. Әмир, А. Шамов, Х. Туфан, Ф. Хөсни иптәшләр Казанның 13 нче номерлы мәктәп укучылары белән очраштылар. Очрашу кичәсендә язучы Афзал Шамов „Фәйрүзә" исемле хикәясен, М. Әмир „Алдакчы бозау" ын, Ф. Хөсни „Сөйләнмәү" хикәясен укыдылар. Х. Туфан иптәш үзенең шигырьләрен укыды.

Балалар язучыларны алкышлап каршыладылар һәм аларның әсәрләрен бик яратып тыңладылар.

13 нче мәктәптә берничә еллар инде әдәбият түгәрәге эшләп килә. Бу түгәрәктән матур гына язып килүче яшь каләмнәр күтәрелделәр. Алар арасыннан Т. Тәрҗеманов, Гарәфи Хәсәнев, М. Әхмәтгалиев кебекләрне күрсәтергә була.

Язучылар белән очрашу кичәсендә дә әдәбият түгәрәге членнары үзләренең әсәрләрен укыдылар. Г. Хәсәнев иптәшнең хикәясе, Ильяс Галиевнең матур шигырьләре язучыларда яхшы тәэсир калдырды.

Балалар әдәбияты декадасы уңае белән шушындый ук очрашу кичәләре шәһәр күләмендә (Пионерлар һәм Мәктәп балалары йортында) һәм тагын берничә мәктәптә үткәреләчәк.

А. Алиш.

ЭНЕРГЕТИКА ҺӘМ ТРАНСПОРТ КАДРЛАРЫ

„Энергокадры" трестының автомобиль мәктәпләрендә промышленность һәм транспорт өчен кадрлар хәзерләнә.

Трестның Татарстан бүлеге узган ел кадрлар хәзерләү планын арттырып үтәде. Барлыгы 1.893 шофер, машинист, электромонтер һәм башка кадрлар хәзерләнде. Автомобиль мәктәбендә инженерлар һәм техниклар укыталар. Укучылар производстводан аерып һәм аермыйча алып барыла. Производстводан аерылып укучылар 3 ай вакыт эчендә шоферлыкка һәм машинистлыкка өйрәнеп җитәләр. Производстводан аерылмыйча укучыларның занятиеләре 6 ай дәвам итә. Быел Казандагы автомобиль мәктәбендә шоферлыкка, машинистлыкка һәм электромонтерлыкка 2.150 кеше хәзерләнәчәк.

Җир промышленностеның технология техникумының анализлар ясау лабораториясендә. РӘСЕМДӘ: 3 нче курс отличникларыннан В. Безруков (сулда) һәм Х. Насретдинова иптәшләр занятиедә.
А. Михайлов фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

„КЫЗЫЛ ТУКУЧЫ" ФАБРИКАСЫН РЕКОНСТРУКЦИЯЛӘҮ

Кукмарада киез итек эшли торган „Кызыл тукучы" фабрикасын киңәйтү өчен яңа корпус салынган иде. Быел бу корпус төзелеп бетә. Аны тәгәлләү өчен 400 мең сум акча җибәрелде. Киез итек эшләүне механикалаштыру өчен яңа машиналар куела.

Узган ел бу фабрика 863 мең пар киез итек эшләп чыгарган иде. Быелгы план буенча 1 миллион пар эшләргә билгеләнде.

СУД

ШӘЛ САТУЧЫ ХАТЫН

Чистайда торучы П. Ф. Васюкова дигән хатын соңгы ике ел эчендә системалы рәвештә спекуляция белән шөгыльләнгән. Ул Иваново өлкәсенең Середа шәһәренә берничә тапкыр барып, трикотаж юбкалар һәм башка товарлар алып кайткан, 19 сум тора торган юбкаларны Чистай районында 30 ар сумга саткан. Шул ук вакытта ул Чистай районыннан Иваново өлкәсенә йон шәлләр алып барган, 90 сумлык шәлләрне 200—300 әр сумга сатып килгән. Соңгы тапкыр Середа шәһәренә барган вакытта аның янында 16 шәл табылган.

Чистай районының беренче участкы халык суды Васюкованы 5 елга иркеннән мәхрум итәргә хөкем итте. Хөкем карары Татарстан АССР Верховный Суды тарафыннан расланды.

КӨНДӘЛЕК ВАКЫЙГАЛӘР

Ерткыч ир. Кызыл Армия районының Каргалы авылында торучы Вагыйз Рәхимов үзенең хатыны Зәйтүнәне һәм 4 баласын системалы рәвештә кыйнап килгән. Бер көнне ул өйдә зур тавыш куптарып Зәйтүнәне бик каты кыйнаган һәм кабыргаларын сындырган. Күршеләр килеп Зәйтүнәне ерткыч ирнең үтерүеннән көчкә хәл белән саклап калганнар. Рәхимов кулга алынып, суд җаваплылыгына тартылган.

ТАТНАРКОМСОБЕС
агротехниклар хәзерләү мәктәбенә,
III нче группа инвалидлардан шушы ел 1 нче мартка кадәр
УКУЧЫЛАР АЛА
Уку срогы 1 ел. Укучыларга стипендия, туклану һәм тулай торакта урын бирелә. Мәктәпкә керүчеләрдән кимендә 5 класс күләмендә белем сорала.
Документлар белән гариза җибәрү өчен адрес: Казан, Тукай урамы, 5, Татнаркомсобес. 351—3—2

Главаптекуправлениенең
— Татарстан бүлеге —
Профсоюз урамындагы 26 нчы йортта (аптекалар үзәк складыбинасына)
КҮЧТЕ
Телефоннар: управляющий 35—36, сәүдә бүлеге 61, Гомуми бүлек 8—20. 236—2—1

Архитектура-Планлаштыру
— мастерскаясы —
(Чернышевский урамы 1, өченче кат, 36 нчы бүлмә)
китайский тушь, Рихтерский һәм башка төрле готовальняләр, шулай ук архитектура буенча китаплар һәм журналлар САТЫП АЛА. Бәяләре килешү буенча, 221—3—2

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ
Бүген һәм һәр көн
РСФСР ның атказанган артисты орденлы
М. ЗОЛЛО
гастрольләре
Яңартылган репертуарда көлке номер:
„МӘЕТ КҮМҮ"
хайваннар башкаруында һәм башка номерлар.
Уен кич 8 дә башлана.
Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 1 гә һәм кич 5 тән 9 га кадәр ачык.

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ
27, 28 һәм 29 нчы февральдә
ЛЕНИН
Бүген талон 110.
Коллектив рәвештә килү өчен заявкалар алына.
Спектакльләр кич 7 сәгат 30 минутта башлана.
Билетлар көндез 11 сәгат 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 7 сәгат 30 минутка кадәр кассада сатыла.

Киров районындагы
КУЛЬТУРА САРАЕНДА
ТДАТ спектакльләре
27 һәм 29 нчы февральдә
БИШБҮЛӘК
Талоннар: бүген 58 һәм 59, 29 нда 60 һәм 61.
Спектакль кич 8 дә башлана.

ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ТЕАТРЫ
Галиәсгар Камал исемендәге Татар Дәүләт Академия театры бинасында
Бүген, 27 нче февральдә ПРИМЬЕРА
ИРЕК
Талон 78
28 нче февральдә
ЗУР КОНЦЕРТ
Талон 79.
Билетлар ТДАТ кассасында сатыла.
Операга коллектив рәвештә килү өчен 29—04 телефоны буенча заявкалар алына. 2—1

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО" 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	ДҮРТЕНЧЕ ПЕРИСКОП
„УНИОН" 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	ХЕЗМӘТ ХАЛКЫ УЛЛАРЫ
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ" 6, 8 һәм 10 да	ДҮРТЕНЧЕ ПЕРИСКОП
„ЧАТКЫ" 6, 8, 9-30 да.	ЗЕЛИМХАН
„ПИОНЕР" 10-50, 1, 2, 4-30, 7 һәм 9-30.	МИНИН ҺӘМ ПОЖАРСКИЙ Көндез 1 сәгаттә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс.
„РОТ-ФРОНТ" 4, 6, 8, 10 да.	БАЛТЫЙКЧЫЛАР
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7, 9 да.	БЕЗ КРОНШТАДТТАН

КИРӘК:
Татнаркомхозның Мелиорация-Гидротехника конторасына ИНЖЕНЕРЛАРДАН: ГИДРОТЕХНИКЛАР, ТӨЗҮЧЕЛӘР, ГИДРОГЕОЛОГЛАР. ТЕХНИКЛАРДАН: ТӨЗҮЧЕЛӘР, ГИДРОТЕХНИК-ИНВЕНТАРИЗАТОРЛАР, САНТЕХНИКЛАР, КОЛЛЕКТОРЛАР, БОРАУЛАУ МАСТЕРЛАРЫ. Шунда ук ЯРДӘМЧЕ ЭШЧЕЛӘР. Казан, Кремль, 3 нче подъезд. 330—5—1

Индивидуаль заказлар буенча аяк киемнәре тегү мастерскоена даими эшкә КВАЛИФИКАЦИЯЛЕ ИТЕКЧЕЛӘР һәм БАШМАКЧЫЛАР. Университет урамы, 2/51. Телефон 11—48. 359—5—2

Казан Нефтебазасына (Яңа бистә, Зур Ямашев урамы, 2) даими эшкә КАССИРЛАР, БОНДАРЬЛАР, СЛЕСАРЬЛАР, КОЧЕГАРЛАР, ОХРАННИКЛАР, ЮРИСТКОНСУЛЬТ, НОРМАЛАУЧЫ, ЭКСПЕДИТОРЛАР, КАМЕРОНЩИКЛАР, ЙӨК ТАШУЧЫЛАР, ДВОРНИК һәм ЯЗУ МАШИНАСЫНДА ЭШЛИ БЕЛҮЧЕ ЭШБАШКАРУЧЫ. Хезмәт хакы килешү буенча. Кирәк кешеләргә тулай торакта урын бирелә. 235—2—2

„Авиапромснаб" Казан конторасының транспорт бүлегенә даими эшкә ШОФЕРЛАР һәм СЛЕСАРЬЛАР. Федосеевский урам, 9. 229—2—2

ТАТАР СОВЕТ КУЛЬТУРАСЫНЫҢ КАЗАНЫШЫ

Бөек рус халкының даһи шагыйре А. С. Пушкинның бөтен дөнья культурасында иң кыйммәтле хәзинәләрдән саналган „Евгений Онегин" романы шагыйрь Фәтхи Бурнаш тарафыннан татар теленә тәрҗемә ителеп, басылып чыкты.

А. С. Пушкин бу роман өстендә сигез ел эшләгән һәм ун меңгә җиткән сүз байлыгының иң күп өлешен шуңа салган. Атаклы тәнкыйтьче В. Белинский бу романга багышлаган мәкаләсендә болай ди:

„Онегин"—Пушкинның иң җылы әсәре, аның хыялының иң сөекле баласы... Монда аның бөтен гомере, бөтен йөрәге, бөтен мәхәббәте, монда аның хисләре, карашлары, уйлары... „Онегин"—рус тормышының энциклопедиясе һәм гаят дәрәҗәдә халыкчыл әсәр..."

Шигырь белән язылган шушындый тарихи зур романны татарчага тәрҗемә итү бөтен татар совет культурасының зур казанышы. Алдан ук әйтеп куйыйк: әсәр яхшы, хәтта бик яхшы тәрҗемә ителгән һәм Татгосиздат та (җаваплы редакторы: шагыйрь Әхмәт Исхак) бөек кыйммәткә ия булган бу әсәрне күңелне шатландырырлык дәрәҗәдә матур итеп чыгара белгән.

Тәрҗемәнең конкрет уңышлары нәрсәдә соң?

Моңарчы „Евгений Онегин"ның татар теленә тәрҗемә ителгәне юк иде әле. Димәк, бу беренче адым. Ләкин, беренче адым булуга да карамастан, иптәш Фәтхи Бурнаш тәрҗемә өлкәсендә мөһим саналган төп мәсьәләләрне бу зур хезмәттә дөрес хәл иткән. Тәрҗемә итүдә Фәтхи Бурнаш Пушкин әсәренең эчтәлеген, мәгънә юнәлешен, әсәрнең эчке рухын дөрес саклау белән бергә, аның шигри формасын да дөрес биргән. „Евгений Онегин" шикелле зур күләмдәге романны тәрҗемә иткәндә эчтәлек белән форманы нык саклый алу, Пушкинга хас булган стильне татар телендә бирергә тырышу,—һич шиксез, зур уңыш.

Романда гаят көчле лирик чигенүләр, гади, ләкин гаят матур сыйфатлаулар берсе артлы берсе тезелеп киләләр.

> Гүзәл йолдызлар күп төн күгендә,
> Матурлар күп шулай Мәскәүдә,
> Тик яктырак бөтен шәмнәрдән дә
> Ай балкыйдыр зәңгәр күкләрдә.
> Бер матур бар, аны, базынмыйм мин,
> Лирам белән һич тә борчымыйм мин,
> Хатын-кызлар белән булганда
> Айдай балкый ялгыз ул анда.
> Ничек матур баса ул җиргә—
> Күкләр горурлыгы битләрендә!
> Ләззәт тулы ничек күкрәгендә!
> Талгын караш нурлы йөзендә!

Татьяна әнә шундый гүзәл. Моны без татар телендә укыйбыз һәм Пушкин белән бергә без дә Татьянаның язмышы өчен кайгырабыз. Без Ленскийның дуэль алдыннан язылган шигырен укыйбыз һәм аның шул кадәр дөрес бирелүенә гаҗәпләнәбез:

> Кая, кая китеп югалдыгыз,
> Язкаемның алтын көннәре?

Романда табигать күренешләрен тасвирлаган искиткеч матур урыннар бар. Татарчада да алар җылы итеп бирелгәннәр.

> Алсу кулы белән инде менә
> Таң күтәрде кырлар аркылы,
> Балкып торган кояш белән бергә
> Туган көннең бәйрәм шатлыгын.

Бу юлларны мин, „татарчада Пушкин поэзиясенең рухы, магнәсе, халыкчыллыгы, җылы гармониясе биреләме, юкмы?" дигән сорауга тәрҗемәнең үз теле белән җавап бирү өчен китердем. Мондый мисальләрне бик күп китерергә мөмкин. Алар саф татарча яңгырыйлар, җиңел укылалар, Пушкин гармониясенә гаят якыннар һәм русча текст белән чагыштырганда да, сүзгә-сүз диярлек, дөрес алынганнар.

Тәрҗемәнең иң беренче уңышлы ягы әнә шунда.

„Евгений Онегин" дүрт строфалы ямба белән язылган. Романда барлыгы сигез глава. Главалар һәрберсе 14 юлдан торган строфаларга бүленә. Һәр строфада иң элек 9—8, 8—9 иҗекле дүрт юллык шигырь килә, ул шушы строфадагы темага кереш булып тора. Аннан теманы дәвам иттерә торган 9—9, 8—8 иҗекле ике пар шигырь бирелә, аннан теманы тутыра торган 9—9, 8—9 үлчәвендә дүрт юллык шигырь алына һәм 8 әр иҗекле соңгы ике юлда темага йомгак ясала. Бөтен роман буена әнә шундый эчке тәртип саклана.

Беренче карауда (бигрәк тә укыганда) бик гади тоелган, ә чынында исә гаят катлаулы булган бу шигырь төзелешен тәрҗемәдә бирү, әлбәттә, кыен нәрсә. Фәтхи Бурнаш әнә шуны бирә алган. Ул „Евгений Онегин" ның җанлы телен иң дөрес чагылдыра торган үлчәү итеп Пушкиндагы 9 иҗекле юлга—10 иҗекле, 8 иҗекле урынына 9 иҗекле шигырь юлларын алган һәм һәр строфада аларның чиратлашып килү тәртибен Пушкиндагыча саклаган.

Тәрҗемәнең икенче уңышлы ягы әнә шунда!

Роман системалы рәвештә килгән катлаулы рифмалар белән язылган. Эченә 6 меңләп шигырь юлын алган романны тәрҗемә иткәндә шигырь техникасының рифма нечкәлеген дә саклау гаят кыен нәрсә. Иптәш Фәтхи Бурнаш әнә шул нечкәлекне, Пушкиндагы шигырь техникасының үзенчәлекләрен шактый оста итеп саклый алган.

Бу зур хезмәт татар телендә кабат-кабат басылыр һәм ара-тирә киткән җитешсезлекләр төзәтелә барыр дип уйлыйбыз. „Татьяна—җанына" шикелле ягымлы булмаган рифмаларга, „файдасы юк Камиллегегезнең" (89 б.) шикелле авыр укыла торган алты иҗекле сүзләргә Бурнаш иптәш игътибар итәр дип уйлыйбыз. Урны-урны белән татар теленә ят булган, яки Пушкин биргән мәгънәне ачып җиткермәгән юллар да очрыйлар.

„Кыш!.. Крестьянин бара күңелләнеп" (110 б.) Беренчедән, татар телендә „крестьянин" дию юк; икенчедән, „күңелләнеп" сүзе русчадагы „торжествуя"ның мәгънәсен биреп бетерми.

> „Яшь гомернең өермәсе кебек,
> Бер үк төсле һаман шашынып."
> (128 б.)

сүзләре белән башланган юллар Пушкин әйтергә теләгән мәгънәне бирмиләр. Пушкинда сүз һаман бер төсле үткән һәм гел шашкын темпта узган вальс турында бара. Ә татарчада моңа бөтән төрле буяу бирелә.

> —„Шагыйрь була язды. Бусын үзем
> Биреп торыр идем аз гына!" (204 б.)

Пушкиндагы „Шагыйрь була язды. Менә бәлә булыр иде, ачык әйткәндә!" дигән фикернең бөтенләй киресе бирелә.

Ләкин кимчелекләр тәрҗемәдә күп урын алмыйлар һәм зур хезмәтнең кыйммәтен дә төшермиләр.

„Евгений Онегин" ның татарчага тәрҗемә ителүе татар совет культурасының тагын да югарырак баскычларга күтәрелә баруын күрсәтә һәм татар совет поэзиясенең үсешенә ярдәм итә. Чөнки „Евгений Онегин" тәрҗемәсендә бирелгән шигырь техникасы, безнең уебызча, шагыйрьләребезгә йогынты ясамыйча калмас: 19, 15 иҗекле шигырь төзелешеннән бүтән төрле үлчәүләргә күчәргә, яңа алымнарда рифмалар өстендә кыюырак эшли башларга ярдәм итәр. Шигырь белән повесть язуда, яки поэмаларда истә калырлык җанлы образлар бирүдә, кайбер әсәрләрне искә алмаганда (мәсәлән, Такташ поэмалары), безнең шагыйрьләребез сәнгать югарылыгына менеп җиткәннәре юк әле. Татар телендә Онегин, Татьяна, Ольга, Ленский образларын уку, аларның мастерларча бирелүен өйрәнү бу эштә, әлбәттә, күп булышлык күрсәтәчәк.

Г. Кутуй.

Җаваплы редактор
Һ. АБДРАХМАНОВ.
Ответ. редактор Х. АБДРАХМАНОВ.